БАЛА ТУМАСА...

Буа районындагы Яңа Чәчкап мәктәбен саклап калып булырмы?

> 6

АКЧАЛЫ СЕРДӘШ

Бушлай белдерү сайтларында бер сәгатькә дус булырга тәкъдим итәләр.

> 7

ШАГЫЙРЬ АНАСЫ

Тукай шәхесенә кагылышлы тагын нинди сәхифәләрне барларга кирәк?

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 57 (28830) | Җомга | 22 апрель | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

«ВТ» архивыннан

ҖИРГӘ ТӨШҮ

ВАЗГЫЯТЬ ЭШЛӘП АШАРГА ӨЙРӘТӘ

Быел яшелчә бәяләре, артып, халыкны аптырашта калдырды. Житмәсә, узган ел бәрәңге уңышы да начар булды. Күпләр орлыклык бәрәңге дә юнәтә алмый калды. Бу сәбәпләр халыкны Җир-анага якынайтырмы? «ВТ» хәбәрчесе шул сорауларга җавап эзләде.

> 5

Ишетми калмагыз

Россиягә дефолт янамый, чөнки аның кирәкле барлык финанс ресурслары бар. Үзәк банк башлыгы Эльвира Нәбиуллина Дәүләт Думасында шулай дип белдергән. Финанс министрлыгы мәгълүматларына караганда, чит илләргә дәүләт бурычы быел 1 февральгә 59,5 миллиард долларны тәшкил иткән. Моңа кадәр финанс министры Антон Силуанов белдергәнчә, «катырылган» валюта счетлары ачылган очракта, бурыч доллар белән түләнeләчәк. Ә инде ачылмаса, Россия үзенең бурычын сумнарда түләргә мөмкин.

Сүз уңаеннан, Дәүләт Думасы Эльвира Нәбиуллинаның вәкаләтләрен тагын 5 елга озайтты. Шулай итеп, ул инде өченче срокка билгеләнде. Нәбиуллина Россия банкы белән 2013 елдан бирле җитәкчелек итә. Закон буенча, бер үк кеше бу вазыйфада күп дигәндә 3 срок эшли ала.

Казан май бәйрәмнәрендә ял итү өчен туристларның иң яраткан шәһәрләре рейтингында 4 нче урынга чыккан. Бу хакта сәяхәтләр оештыру буенча OneTwoTrip онлайн хезмәте хәбәр итә. Сәяхәтчеләрнең 18 проценты майда Санкт-Петербургта ял итәргә теләк белдергән. Икенче урында – Мәскәү. Ял итәргә ниятләүчеләрнең 12 проценты башкалага юл тотарга җыена. Сочи өченче урынга чыккан (9 процент). Туристларның 5,3 проценты Казанны сайлаган.

Казан мэры Илсур Метшин белдергәнчә, башкала елына 5 миллион туристны кабул итүгә омтылырга тиеш. Узган елда Татарстан башкаласында 3 миллионнан артыграк кунак булып киткән.

Татарстан вузларына яңа уку елына бакалавриат, специалитет һәм магистратура программалары буенча барлыгы 20788 бюджет урыны бирелгән. Мәгариф һәм фән министрлыгы шул хакта хәбәр итә.

Бюджет урыннары барыннан да бигрәк мәгариф һәм педагогика фәннәре (12 процент), информатика һәм исәпләү техникасы (8 процент), электр һәм җылылык техникасы (7 процент), химия технологияләре (7 процент), машина төзелеше (4,5 процент) юнәлешләре буенча бирелгән.

Гомумән, соңгы 3 елда республика вузларында бюджет урыннары саны 20 процентка арткан. Үзгәреш Россия Президенты Владимир Путин куйган бурычны үтәүгә бәйле.

Явымлы, суык һава чигенә. Ял көннәрендә Татарстанда җылы һава урнашачак: һава температурасы +17 градуска кадәр күтәреләчәк. Явым-төшем көтелми. Шимбә – 23 апрельдә көндез +10...+15 градус булса, төнлә термометрның терекөмеш баганасы 0...–5 градус күрсәтәчәк. Якшәмбедә көндез +12...+17 градус, төнлә –3...+2 градус.

Татарстан Гидрометеоүзәгенең баштангыч фаразына караганда, киләсе атна башында урыны белән аз гына яңгыр булырга мөмкин. Дүшәмбе – 25 апрельдә көндез +10...+15 градуска кадәр җылыта, төнлә дә җылы: +2...+7 градус. Сишәмбе – 26 апрельдә көндез +14...+19 градус.

КФУ метеорология кафедрасы доценты Тимур Әухадиев әйтүенчә, апрельнең унҗиде көнендә Казанда явым-төшем ике айлык норманы «тутырган». Метеокүзәтүләр тарихында моңарчы андый хәлнең күзәтелгәне булмаган.

Районнарда ни хәлләр?

Әлмәт

Нефтьчеләр башкаласында социаль ипотека программасы буенча төзелгән ике йортны кулланылышка тапшырдылар. Автомобильчеләр урамында урнашкан 298 һәм 63 фатирлы бу йортларда нефтьчеләр яшәячәк. Яңа фатирларның һәркайсында сантехника, газ плитәсе, янгын хәбәрчеләре, шулай ук су, газ, электр энергиясе һәм җылылык белән тәэмин итү исәпләгечләре бар инде. Татарстан Президенты карамагындагы Дәүләт торак фондының башкарма директоры Марат Зарипов әйтүенчә, 2024 елга кадәр Әлмәттә нефтьчеләр өчен 1160 фатирлы 6 йорт төзү планлаштырыла.
(«Әлмәт таңнары»)

Яшел Үзән

Татарстанда беренче тапкыр «Катык» этнография фестивале булачак. «Якын күршеләребез – Чуашстан һәм Мари Иле вәкилләрен дә чакырырга телибез. Алар да фестивальдә милли ризыкларын, сувенир эшләнмәләрен күрсәтәчәк. Фестивальнең төп вакыйгасы – зур казанга салынган катыкны тәкъдим итү һәм аны борынгы рецепт буенча әзерләү турында сөйләү. Бу сөт ризыгын фестивальгә килгән һәр кеше дә татып карый алачак», – ди Яшел Үзән районында урнашкан «Татар авылы» музее директоры Миңнедамир Камалетдинов. Фестивальне август башында уздырырга ниятлиләр.
«Татар-информ»

Мамадыш

Районның белем бирү оешмаларының 979 укучысы бушлай ял итү, күңел ачу һәм башка учреждениеләргә бару хокукы бирә торган бердәм шәхси билеттан файдалана. Район башлыгы Анатолий Иванов карары нигезендә, бу документны күпбалалы, аз тәэмин ителгән гаиләләрдән булган, физик мөмкинлекләре чикләнгән һәр бала алырга тиеш. Мондый билетка ия булганнар тренажер залына, «Олимп» спорт сараена, шугалакка, бассейнга, кинозалларга, яр буендагы аттракционнарга, музейга, мунчага, пляж комплексына бушлай керә ала, шулай ук чаңгы, тимераяк, самокатлар, ролик тимераякларын, велосипедларны прокатка алган өчен дә түлисе түгел.
(mamadysh.tatarstan.ru)

Кайбыч

Шушы көннәрдә җирлекнең мөстәкыйль район булып оешуының 31 еллыгын билгеләп уздылар. Бәйрәм чарасын ел да зурлап, алдынгыларны данлап, истәлекләр барлап, концерт чарасы белән үткәрәләр. Оештыручылар әйтүенчә, өч дистә ел элек бер үк вакытта оешкан районнар арасында бу вакыйганы ел саен үткәрә торганнары сирәк. Бу – Кайбыч районының традициясе, якташларны туплау-җыю, очрашу урыны да. Бәйрәмдә Кайбыч районы башлыгы Альберт Рәхмәтуллин алдынгыларны бүләкләде, рәхмәт сүзләрен җиткерде. «Кайбычның төп байлыгы – аның үсеше өчен тырышучы, туган җирен яратучы кешеләре», – диде ул.

БЕРГӘЛӘП ЭШЛИСЕ

Экологиягә бәйле проблемаларны уңышлы хәл итү өчен, сәнәгать предприятиеләренең фәнни даирәләр белән берлектә эшләве кирәк.

tatarstan.ru

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Түбән Камага эшлекле сәфәре барышында шулай дип белдерде. Биредә ул Россия Фәннәр академиясенең (РФА) глобаль экологик проблемалар буенча фәнни советы һәм Түбән Кама сәнәгать узелын үстерүдә экологик иминлекне тәэмин итү буенча ведомствоара даими эш төркеме әгъзалары утырышында катнашты.

Рөстәм Миңнеханов утырышта басым ясап әйткәнчә, Түбән Кама сәнәгать узелы нефть-газ-химия производствосы үзәге булып тора. Сәнәгать продукциясенең 60 проценттан артыграгын республикага нефть-газ-химия тармагы бирә. «Производстволарны тотрыклы үстерү, экологик иминлекне тәэмин итү мәсьәләләренә игътибарның артуын күреп торабыз. Экологиягә сакчыл мөнәсәбәтне күздә тоткан технологияләргә ихтыяҗ арта», – диде ул.

Президент билгеләп үткәнчә, дәүләт программаларында еш кына «индустриаль партнер» төшенчәсе кулланыла. Сәнәгать белән фән арасында тыгызрак хезмәттәшлек кирәклеге турында сөйли бу. «Фән һәм бизнес бер йодрыкка тупланып эшләгәндә генә, катлаулы бурычларны уңышлы хәл итәргә мөмкин. Татарстанның нефть-газ-химия комплексы предприятиеләре мондый хезмәттәшлекне үстерү белән кызыксына», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Ул бүген икътисадның Көнбатыш илләре тарафыннан бик көчле басымга дучар булуын искә алды. Иң элек, шул исәптән экологик мәсьәләләрне хәл итү өчен, чит ил технологияләренә, җиһазлар һәм материалларга юлның ябылуын аңлата бу. Әлеге юнәлештә уртак эшләү өчен зур мөмкинлекләр барлыгын әйтте Президент.

«Алга таба хезмәттәшлекнең, табигатькә зыянны киметү максатында, «яшел» технологияләрне, цифрлы чишелешләрне гамәлгә кертүгә, шулай ук энергия һәм ресурсларны сак тоту өлкәсендә проектларны тормышка ашыруга ярдәм итәчәгенә ышанам», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Татарстанның экология һәм табигать ресурслары министры Александр Шадриков әйтүенчә, соңгы өч елда табигатьне саклау чараларына 30 миллиард сум акча тотылган. Республика бу күрсәткеч буенча Идел буе федераль округында алдынгы урынны били. 2019–2021 елларда «Экология» илкүләм проектын тормышка ашыру кысаларында Татарстанда 7 миллиард сумнан артыграк акча тотылган. «Экологик иминлек Татарстан предприятиеләре өчен дә өстенлекле бурыч булып тора. Өч ел эчендә алар шушы максатка 20 миллиард сумнан артыграк акча тотты», – диде министр.

Түбән Кама районы башкарма комитеты җитәкчесе Рамил Муллин сүзләренә караганда, шәһәрдә химик технологияләр буенча заманча фәнни үзәк оештыру күздә тотыла. Түбән Кама химия-технология институты базасында фән-мәгариф кампусын булдыру әлеге эшнең беренче этабы булачак.

РФАнең глобаль экологик проблемалар буенча фәнни советы рәисе Степан Калмыков та Татарстан предприятиеләренең табигатьне саклауга зур игътибар бирүенен һәм бу өлкәдә хезмәттәшлекне үстерүгә әзер булуын әйтте. Түбән Камада Татарстан Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы белән РФАнең глобаль экологик проблемалар буенча фәнни советы арасында килешү имзалану да шуны раслый.

«ТЕЛЕГЕЗ ШИГЫРЬ КЕБЕК»

Татар теле һәм әдәбиятыннан IX Халыкара олимпиаданың Гран-при ияләре булып Биектау районының Мүлмә мәктәбе укучысы Гөлинә Минҗәләева, Пермь краеннан Ләйлә Нажина һәм Төркиядән Искешәһәр Османгази университеты магистры Гамзә Нур Налбант танылды.

– Мин – төрек кызы. Кояшлы Төркиядән килгән булсам да, карлы Татарстан һәм Казан һәрвакыт минем хыялымда яшәде. Һәм, ниһаять, мин монда. Хыялым тормышка ашты, Аллага шөкер. Мәктәптә укыган чакта татарча җырлар тыңлап, телегезгә гашыйк булдым. Бу да бит – төрки тел, нигә мин аңлый алмыйм, дип елый идем. Шуннан соң төрки телләрне аңлый башладым. Хәзер берничә телдә сөйләшә алам. Ләкин татар теле минем өчен – иң мөһиме. Мин – магистрант. Татар шагыйрьләренең шигырьләрен төрекчәгә тәрҗемә итәм, татар теле турында мәкаләләр язам. Алла боерса, гомер буе татар теленә хезмәт итәчәкмен. Төрекләргә – татарча, татарларга төрекчәне өйрәтәсе килә. Казан Кремлен, Колшәриф мәчетен, Сөембикә манарасын күргәч, үземне Алтын Урда, Болгар, Казан ханлыгы чорында яшәгән кебек хис иттем. Мондый мөмкинлек тудырган өчен Татарстан Республикасына рәхмәт. Татарлар, кардәшләрем, телегез шундый матур, шигырь кебек. Аны онытмагыз! Теле яшәгән халык яши. Татар халкы мәңге яшәсен, – диде Гамзә Казанда узган бөтенроссия туган телләр форумында.

Пермь өлкәсенең Тортүз авылыннан килгән Ләйлә Нажина: «Мин – татар авылында, татар гаиләсендә туып-үскән авыл кызы. Киләчәгемне татар теленнән башка күз алдына китерә алмыйм. Өйдә бары татарча гына сөйләшәбез, мәктәптә татарча укыйбыз», – диде. Ләйлә олимпиадага дәресләрдән соң ныклап әзерләнгән. Киләчәктә мал табибы булырга хыялана.

– Казанга килеп, татар гаиләсе корасым, татарча сөйләшәсем килә. Монда миңа бик ошый. Үземне өйдәге кебек хис итәм, – диде Ләйлә.

Биектау районының Мүлмә авылы кызы Гөлинә киләчәген татар журналистикасы белән бәйләргә җыена. «Башта артык тырышмаган идем. 9 нчы сыйныфта олимпиадага җибәрделәр. Беренче елны уңыш елмаймады, 10 нчы сыйныфта призер булдым. Быел Гран-при оттым», – дип сөенә Гөлинә.

Олимпиадада җиңүчеләргә өстенлекләр каралган: уку йортларына укырга кергәндә татар теленнән сынау булмый. Идел буе Физик культура, спорт һәм туризм академиясендә узган чарада Татарстанның мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин әнә шулай диде. Олимпиадага илнең 28 төбәгеннән – 138, республикадан 280 укучы килгән. Төркия, Казахстан, Кыргызстан, Азәрбайҗан, Австралиядән 12 укучы катнашкан. «Шунысы сөендерә: ел саен катнашучылар саны арта бара. Татар теленә мөнәсәбәт үзгәрми. Аны үстерүдә, татарның киләчәген саклап калуга юнәлтелгән чараларны вакытында үткәрүдә татар теле укытучыларының роле зур. Без олимпиадада татар теленә мөнәсәбәтебезне күрсәтәбез. Биредә татар халкына мәхәббәт белән караган кешеләр җыелган», – диде Илсур Һадиуллин.

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татарстан Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов халыкара олимпиаданы зур вакыйга дип бәяләде.

– Әгәр Тукаебыз исән булса, телебезнең, традициябезнең киләчәгенә өмет барлыгына ышанып, ничек сөенгән булыр иде! Мәгариф министрлыгы телебез язмышы, киләчәге өчен зур эш башкара. Киләсе елда, унынчы юбилей елында, тагын да чаралар күрербез. Һәр катнашучы – татарның алтын баганасы. Телебез бар, ул шулай булырга тиеш, – диде Марат Әхмәтов.

Сәрия МИФТАХОВА

ТЫЛСЫМЛЫ ТАЯК ТАБЫЛЫРМЫ?

Матур саннар тормыш сыйфатында чагылыш тапканмы? Татарстан Дәүләт Советының 31 нче утырышында шул хакта сөйләштеләр. Моннан тыш, гадәттәгечә, федераль һәм республика законнарына үзгәреш-төзәтмәләр кертүне карадылар. Утырыштагы төп чыгыш исә башкарма хакимиятнең былтыр башкарган эшләре турында булгандыр.

gossov.tatarstan.ru

Татарстанның вице-премьеры Ләйлә Фазлыева Дәүләт Советы утырышында республиканың иң яхшы һәм иң начар бюджет оешмаларын атады. Бу – халык фикеренә таянып әзерләнгән сораштыру нәтиҗәләре икән.
Мәдәният өлкәсендә иң яхшы оешма булып Милли китапханә танылган. Аннан соң Алабугадагы тарих-архитектура музей-тыюлыгы. Өченче урында – Казан Кирмәне.
Сәламәтлек саклау тармагында яхшы сүзне иң күбе республиканың офтальмология хастаханәсе ишеткән. Икенче урында – онкология диспансеры. Өченчедә – төбәкара клиник диагностика үзәге.
Белем бирү өлкәсендә Чаллыдагы педагогика көллияте, Чистайдагы балалар йорты, Чаллыдагы технологик техникумга тиңнәр булмаган.
Иң начар эшләгән учреждениеләр исемлегендә исә Чистайдагы музей-тыюлык, Кайбычтагы музей, Казанның 20 нче һәм 8 нче номерлы сырхауханәләре телгә алынды.

Ә алар начар эшләмәгән. Татарстан Премьер-министры Алексей Песошин хисабыннан шул аңлашылды.

– Рубль курсының үзгәрүчәнлегенә (волатильность), энергетика ресурсларына бәя үйнауга, катлаулы эпидемиологик вазгыятькә карамастан, 2021 елда Татарстан икътисады 2019 елгы – пандемиягә кадәрге күрсәткеченә әйләнеп кайтты, – диде Хөкүмәт Рәисе.

Саннарга күз салсак, Эчке төбәк продукты (ВРП) – 3,8 процентка (3,35 трлн сум) үскән. Татарстанда хезмәт хакы күләме 6 процентка арткан. Шуның белән бергә эшсезлек күрсәткече 3,5 тапкыр кимегән. 38,7 мең эшсездән 11,4 меңе генә калган. Төзелеш тармагының да рекорд куйганы билгеле: былтыр 3 млн квадрат метрдан артыграк торак файдалануга тапшырылган. Төбәк юлларында эш туктап тормаган, хәтта сизелерлек арткан да. Мәсәлән, 91 чакрым яңа юл салынып, тагын 854 чакрымы төзекләндерелгән. Яңа алты күпер салынган, М-12 трассасы, Горький шоссесы дублер юлы, Вознесение тракты, Зур Казан боҗрасы төзелеше дәвам итә. Яңа корылмаларның сафка басуы, искеләрен яңарту да туктамаган. 17 яңа балалар бакчасы һәм 7 мәктәп ачылган, 70 җәмәгать урыны төзекләндерелгән, 1 меңләп ишегалды тәртипкә китерелгән, 959 күпфатирлы йортка ремонт ясалган.

Җәй коры килсә дә, авыл хуҗалыгы тармагына караган күрсәткечләрдә республика алдынгылыгын саклап кала алган. Әйтик, сөт җитештерү буенча – 1, бәрәңге үстерүдә – 2, терлек һәм кош ите буенча – 6, йомырка җитештерү буенча – 7 нче урыннарны били Татарстан.

Барлык дәрәҗәдәге бюджетларга 1,35 трлн сум тирәсе акча тупланган, шуның 336,8 млрд сумы төбәк бюджетына күчерелгән. Моңа өстәп, барлык дәүләт программалары да үз көчендә калачак, аз керемле, күпбалалы гаиләләргә ярдәм итү (республика бюджетының һәр икенче сумы шуларга тотыла. – Авт.) тормышка ашырылачак, дип вәгъдә итте Алексей Песошин.

Премьер-министр чыгышыннан соң депутатлар аңа сорау-тәкъдимнәрен җиткерде. Кайсылары илкүләм проектлар өчен борчылды, кемдер укытучылар өчен хезмәт хакын арттырып булмасмы, дип кызыксынды, алданган өлешчеләр мәсьәләсен кузгатты. Яңа торак комплексларда мәктәпләр җитмәвен дә искә алдылар.

Ни булса да, ирешелгән күрсәткечләрнең халыкның тормыш сыйфатына уңай тәэсир итүе булсын. Башкарма хакимияттән алга таба да әнә шуны көтәләр булып чыкты. Депутатлар чикләүләрнең чикләнмәгән мөмкинлекләргә китерәсенә дә ышанычын әйтте. Тылсымлы таяк булмас – үзебезгә ышану, бердәм булу сорала икән.

Былтыр да җиңел булмады. Быел тагын да кыенрак булачак. Сәбәпләре һәркемгә мәгълүм инде. Моны аңлап, Фәрит Мөхәммәтшин да республиканың күпьюнәлешле икътисадын саклап калу өчен көч түгәргә туры киләчәге турында кисәтеп куйды.

– 2022 ел, мөгаен, җиңелрәк булмас. Хәтта «мөгаен» сүзен дә алып ташларга кирәктер. Санкцияләр дәвам итә. Нефть чыгаруны һәм эшкәртүне дәвам итәбез, самолетлар, вертолетлар да ясыйбыз, машина төзелешен үстерәбез. Безнең өчен алда җитди бурычлар тора, – диде ул һәм республика Хөкүмәтен быел да актив эш алып барырга, импортны алмаштыру юнәлешендә эшләргә, 2030 елга кадәр төбәк үсеше стратегиясендә күрсәтелгән барлык бурычларны үтәргә чакырды.

Депутатлар көн кадагындагы тагын бер мәсьәләгә аерым тукталды һәм ДНР, ЛНР, Украинадагы махсус хәрби операция уңаеннан Россия Президенты Владимир Путинга теләктәшлек белдереп, мөрәҗәгать кабул итте. Бу җәһәттән Парламент Рәисе: «Ул – ил башлыгына да, Россиягә дә кирәк мөрәҗәгать. Ул безнең халык өчен дә кирәк, алар дәүләтчелекне ныгыту, аны саклау һәм какшатмау юнәлешендә ныклы фикердә торуыбызны күрсеннәр», – дип белдерде.

Фәрит Мөхәммәтшин утырышта депутатларга: «Исән кешегә яңа сайлаулар да килеп җитәчәк ул», – дип әйтеп куйды. Дөрес әйтә. Яңа сайлау белән бергә яңа сораулар, мөрәҗәгать-гозерләр дә туачак. Халык сайлаган депутатлар моңа әзер торырга тиеш. Дөньясы гына тыныч булсын. Кабат кайта торган сораулар ачык калды бит әле.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы һәм Украина территорияләрендә махсус хәрби операция үткәрелүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясе Президенты В.В.Путинга теләктәшлек белдерү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгате турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ**:

1. Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы һәм Украина территорияләрендә махсус хәрби операция үткәрелүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясе Президенты В.В. Путинга теләктәшлек белдерү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгатен (кушымта итеп бирелә) кабул итәргә.
2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Президенты В.В. Путинга җибәрергә.
3. Әлеге карарны республика массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2022 елның 21 апреле
№ 1411-VI ДС

Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы һәм Украина территорияләрендә махсус хәрби операция үткәрелүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясе Президенты В.В. Путинга теләктәшлек белдерү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы МӨРӘҖӘГАТЕ

Без, төрле партияләр һәм киң җәмәгатьчелек вәкилләре булган Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары, махсус хәрби операция үткәрелүгә бәйле рәвештә халыкара мәйданда барлыкка килә торган вазгыятькә борчу белдереп, дәүләтебезнең илкүләм лидеры, Югары Башкомандующий, Россия Федерациясе Президенты В.В. Путинның Украинадагы хәрби куәтне һәм нацизмны бетерү, Донецк һәм Луганск халык республикалары халкына һәрьяклап ярдәм күрсәтү курсына теләктәшлек белдерәбез.

Күрше дәүләт территориясендә баручы вакыйгалар, «Кырым язы» тәҗрибәсе кебек үк, алдан күреп махсус хәрби операция үткәрүнең сигез ел буе милләтче формированиеләр тарафыннан Украина көнчыгышында геноцидка дучар ителгән тыныч халыкны үтерүне туктатырлык бердәнбер дөрес, стратегик яктан һәрьяклап үлчәнгән карар булганын дәлилли. Россия хәрбиләренең хәлиткеч гамәлләре тагын да күбрәк корбаннар булдырмауга, Донбасска, Кырымга каршы әзерләнгән һөҗүмнәргә юл куймауга, Россия Федерациясенең илкүләм иминлеген тәэмин итүгә ярдәм итте.

АКШ җитәкчелегендә Көнбатыш илләре, берьяклы мәгълүматларга, фейкларга һәм ачыктан-ачык провокацияләргә таянып, дәүләтебезгә каршы тулы масштаблы икътисади һәм мәгълүмати сугыш башлап җибәрде. Моңарчы күрелмәгән санкцияләр кертелде, Россия Федерациясен халыкара дәрәҗәдә изоляцияләргә тырышу бара. Шул ук вакытта төп бурычларның икътисадны какшату, тормыш эшчәнлегенең барлык тармакларында тотальк кризис вазгыятен булдыру һәм ахыр чиктә Россия Федерациясенең дәүләтчелеген җимерү икәнлеге яшерелми.

Әлеге вазгыятьтә, Украинага шактый күләмле финанс чаралары җибәреп һәм аны корал белән тәэмин итеп, безгә дус булмаган илләр, бернигә дә карамастан, гамәлгә ашмаган Киев режимын сакларга омтылалар. Күпсанлы корбаннар һәм тыныч халыкның газаплары – бу сәясәтнең куркыныч һәм котылгысыз бәһасе.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары әлеге шартларда халкыбызның берләшүен, бердәм булуын аеруча мөһим дип саныйлар. Без Россия Кораллы көчләренең Югары Башкомандующий тарафыннан куелган барлык бурычларны намус белән үтәүләренә ышанабыз. Ватаныбызны саклаучыларның көндәлек батырлыгы патриотизмның, антка тугрылыкның, тугандаш халыкка ярдәмгә әзер булуның иң якты үрнәкләренең берсе булып тарихка кереп калачак. Татарстан халкы үзенең каһарманнары белән горурлана һәм батырларның һәлак булуына тирән кайгы кичерә. Республика, һәлак булган хәрбиләрнең туганнарына һәм якыннарына ярдәм күрсәтүне үзенең бурычы дип санап, һәлак булганнарның гаиләләренә Идел буе федераль округында беренчеләрдән булып өстәмә региональ түләүләр кертте.

Донбассның азат ителгән территорияләре халкына мөмкин кадәр ярдәм итәргә омтылышта Россия Федерациясенең барлык субъектлары бердәм караштa тора. Гуманитар ярдәм күрсәтүдә актив катнашучы безнең регионда бу эштә барлык дәрәҗәдәге гавами хакимият, предприятиеләр, партияләр һәм иҗтимагый оешмалар катнаша. Татарстанлылар әйбер җыю пунктларына продуктлар, дарулар, кием-салым һәм шәхси гигиена әйберләре, китаплар, уенчыклар китерә. Хәзерге вакытта сигез йөк машинасында гомуми авырлыгы 100 тоннадан артык булган беренче чиратта кирәкле товар җибәрелде.

Республика мең ярымнан артык мәҗбүри күченеп килүчене кабул итте. Аларга барлык кирәкле медицина ярдәме, социаль ярдәм күрсәтелә, балаларны балалар бакчаларына һәм мәктәпләргә урнаштыруда, эшкә урнаштыруда булышлык күрсәтелә.

Хәзерге вакытта икътисадның тотрыклылыгын саклап калу, гражданнарны социаль яклау дәрәҗәсен арттыру буенча илнең Президенты һәм Хөкүмәте тарафыннан чаралар комплексы гамәлгә ашырыла. Татарстанда кризиска каршы штаблар эшли, дәүләт хакимияте һәм муниципаль хакимият органнары тарафыннан тотрыклылыкны тәэмин итү буенча гамәли адымнар ясала.

Әлеге чараларның барысын да хуплап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары илебезнең халыкара мәйданда тоткан урынын ныгытуда, Россия Федерациясе күпмилләтле халкының иминлеге һәм мәнфәгатьләре хакына куелган максатларга ирешүдә актив катнашалар.

Әйтеп кенә бактым

Риман
ГЫЙЛЕМХАНОВ

«Кеше кулына калырга язмасын»

Әбием Мәүлиха гомеренең соңгы елларында шушы сүзләрне еш кабатлады. Бер уйлаганда, аның «кеше кулы» дигәне дә ят куллар түгел иде. Әти-әни дә, без – оныклары да бик яраттык әбине, мөмкин кадәр тәрбияләдек, аның җаена гына тордык. Әмма әби Ходайдан бары бер генә нәрсә сорады: «Раббым, кеше кулларына калдырма, аз сырхау, ансат үлем бир!» – ди иде.

Бүген дөньялар тынычсызланган-буталган заманда әбием сүзләрен еш искә төшерәм. Баксаң, безнең ил дә инде күптән кеше кулына калган икән бит һәм бу «куллар» – безне хөрмәт иткән түгел, ә дошман күргән дәүләтләрнең «куллары». Без баш-аягыбыз белән кемгәдер бәйле икән бит!

Күршебез Шәймулла абый алдынгы механизатор иде, рәсеме район үзәгендәге Почет тактасында торды. 25 ел бер комбайнда эшләде ул, комбайны ватылса, еш кына басуда да төзәтер иде. Ә лапасында нинди генә эш кораллары юк иде аның! Хәтта, кирәге чыкмагае дип, һәртөрле тимер-томыр да җыйды ул. Берәр нәрсә кирәк булса, бөтен күрше-тирә шуның янына керде. Берәр эшкә тотынгач, кайчак әти дә: «Улым, булса, Шәймулла абыеңда гына булыр, бар, кереп чык әле!» – дип, еш әйтә иде миңа. Күрше-тирә әнә шулай Шәймулла абыйга бәйле иде. Ә үзе, кирәкярак сорап, берәүгә дә кермәде. Әнә шулай берәүгә дә бәйле түгел иде күршем.

Бу хәлне мин бүген дөньядагы илләр дәрәҗәсенә күтәреп карыйм. Россиягә карата берблер артлы кулланылган санкцияләр илнең ни дәрәҗәдә «кеше кулына» калуын күрсәтте.

Беркөнне Дәүсоветның Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты утырышында булдым. Анда «импортозамещение» дигән сүзләр шактый мул яңгырады. Иң шаккатырганы – безнең кошчылык тармагы да шактый ук дәрәҗәдә чит илләргә бәйле икән. Инкубатор күкәйләренең 60 проценты чит илдән кайтарыла. Ә мәгълүм булганча, хәзер күп кенә илләр безгә «этлек эшләргә» генә тора. Димәк, күкәй мәсьәләсе шактый ук дәрәҗәдә баш авыртуына әйләнергә мөмкин. Министрлык вәкиле күңелне бераз тынычландырды үзе, күкәй запасы ике елга җитәрлек, диде. Ә аннан соң нишләргә? Ярый әле дуңгызчылык тармагында хәлләр алай ук зарланырлык түгел, ди. Безне шул дуңгыз коткарса гына инде.

Безнең кебек кемгәдер бәйле илләр тагын бардыр. Әмма дөньяда тиңе булмаган сугыш кораллары ясый алган илнең, мәсәлән, көндәшлеккә сәләтле җиңел машиналар да эшләп чыгара алмавы, авыл хуҗалыгы техникасы җитештермәве бик сәер тоела. Без хәтта кайбер яшелчәләрне, кадак-игәүләрне дә читтән кайтара башладык. Хәтта Мәскәү телеканалыннан бара торган, заманында «иң яңа проект» дип тәкъдим ителгән «Поле чудес» кебек тапшыруларның идеясен дә чит илдән алдык.

Бүтән мисаллар китереп тормыйм. Инде менә килеп терәлдек. Президент Владимир Путин әйтмешли, «Күк күкрәми – мужик чукынмый» дигән әйтем – безнең хакта. Инде менә «чукына-чукына» эшкә тотынып заманнар килеп җитте.

Һаман да зарланып кәефне төшерәсе килми. Без гаҗәп бай илдә яшибез, табигый байлыкларыбыз бихисап, халык тырыш. Бүген илгә килгән авырлыкларны җиңеп, тагын да куәтләнербез дигән өмет бар.

Менә шулай үзем күңелне тынычландырам, әмма Мәүлиха әбиемнең әйткәннәре, бар нәрсәне үзеңдә булдырып бәйсез яшәргә өйрәнгән Шәймулла абый барыбер искә төшкәләп куя, чукынчык.

БЕЛМИМ, ӘЛЛӘ КҮПКӘ, ӘЛЛӘ БИК ОЗАККА...

24 февральдән соң хәлләр катлауланып, күңелләрдә «тагын да начаррак булмасын» дигән шом яши башлагач, кешеләр бер сорауны бик еш бирә: «Тиз бетәр микән бу матавыклар, озакка барыр микән?..»

Аңлашыла инде: йөрәкләр авырлыкларның тиз бетүен тели. Ай-яй-яй, бирмәгез бу сорауны, бирмәгез! Һәм авырлыкларның тиз бетүенә өметләнмәгез, чөнки бу юлларны язучы концлагерьлар аша үткән Австрия психотерапевты Виктор Франклның сүзләрен белә. «Беренче булып, – ди ул, – барысы да тиз бетәр дип ышанганнар сынды. Аннан соң бу кайчан да булса бер бетәр дип ышанмаганнар… Бары тик тагын нәрсәләр булыр икән дип көтмичә, үз эшләренә бар игътибарын юнәлткәннәр генә исән калды».

Без, әйдәгез, яшәүне сайлыйбыз: сазлыктан тиз генә чыга алмабыз, әмма авырлыклар мәңгегә килмәде, дип ышанабыз. Шуңа күрә билләрне кысып буып, җиңнәрне сызганабыз да алга таба барабыз. Җиңнәрне яхшылап сызгансак, бәлки билләрне артык нык кысып буарга да туры килмәс… Әлегә «кино»ның икенче сериясе генә бара, өченче һәм дүртенче серияләр дә бар… Бу – шундый «кино»: анда атылган уклар безнең өстән дә оча. Һәр сериядә уклар ешрак атылачак… Әмма Аллаһы Тәгалә әйтә (мәгънәсе): «…сиңа ирешкән катылыкка, бәла-казаларга сабыр ит…» (31 нче сүрә, 17 нче аять). Аңлаган кешеләргә һәлакәттән котылуның иң яхшы формуласы шул инде.

Бу язмада без аның башына чыгарылган юлларга бераз гына җавап бирүне максат итеп куйдык. Нәрсәләрнең кайчан башланасын, кайчан бетәсен бу юлларның авторы да белми, әлбәттә. Без бары тик вакыйгаларның үсеш мантыйгыннан аларның кай якка таба борыласын чамаларга гына тырышабыз. Кыска сроклы перспективада матди хәлләрнең кая таба юнәләсен (хәрби өлкәгә без кысылмыйбыз, анысы – хәрби аналитиклар эше, безнеке түгел) Үзәк банк рәисе Эльмира Нәбиуллина Дәүләт Думасында ясаган чыгышка нигезләнеп чамалап карыйк. Эльмира ханымның дошманнары бик күп, әмма дөрес булса, вазгыять бик кайнарланган вакытта Кремльдә үз позициясен курыкмыйча әйтә алган бердәнбер шәхес шул диләр. Думада да ул, алсу күзлекләр киеп тормыйча: «Икътисадның запасларда яши торган периоды чикләнгән. Һәм II кварталда – III кварталның башында ук без структур трансформация һәм бизнесның яңа модельләр эзләү периодына керәчәкбез», – дип белдерде, Үзәк банкның теләсә нинди ысул белән инфляцияне чикләргә тырышмаячагын, ахыргы продукциягә бәяләрнең кыйбат булу ихтималлыгын игълан итте. Иң мөһим урынны тәрҗемәсез бирик: «Наша экономика вступает в непростой период структурных изменений, связанных с санкциями». Күз яшьләре түгү юк бу юлларда, ак болытлар өстендә очу да юк. Эшләргә туры киләчәк һәм бетте китте… Җиңел булыр дип өметләнергә ярамый.

2014 елны хәтерлик әле. Санкцияләр кертелә башлагач, илкүләм рәвештә «импортны алыштыру» проектлары белән мәш килдек. Министрлыкларның идән асларында шундый проектлар язылган кәгазьләр папка-папка, тау-тау булып өелде. Сигез елдан соң ирешелгәннәрне карыйк. Үткән еллар эчендә чит базарлардан ерагаймагабыз гына түгел, кендегебез белән берегеп, кендеккә муеныбыздан чорналып беткәнбез. Ипи заводларының җиһазлары тулысынча импорттан, берничә айдан соң аларны ремонтларга комплектлаучы детальләр булмаганлыктан, икмәк дефицитка әверелергә мөмкин. Яисә совет чоры җиһазларын торгызабыз да… Хәзерге яшьләр белми: авыл кибетләрендәге ипине авызга алырлык түгел иде, шәһәр кибетләрендә сыйфатлырак иде анысы. Шул сыйфатсыз ипинең дә кайтуын иртәдән кичкә кадәр көтә һәм бер кулга санаулы гына итеп ала идек. Үзең пешерим дисәң, оны юк, оны булса, чүпрәсе дефицит иде.

Менә «Коммерсантъ» яза: «Россиянең азык-төлек җитештерүчеләре 60–100 процентка Евросоюздан чимал импортына бәйле». Безнең рәсми чиновниклар да раслый моны: ипи пешергәндә дә камырга салу өчен чит илләрдән алырга туры килгән ноксыраклар байтак, диләр. Медицина пирчаткәләре бетә, дип чаң сугучылар бар. Кирәкле 500 миллион пар пирчаткәнең 1 проценты гына үзебездә җитештерелә. Мондый дефицит СССР заманында да юк иде. Болары мин 2014 елда иҗат ителгән импортны алыштыру проектларының ничек тормышка ашырылуын дәлилләү өчен генә язам. «Иҗат»ны чиновниклар кулына бирсәк, алар бик мавыктыргыч идеяләрдән торган проектлар язачак, әмма йөк һаман да үз урынында калачак. Базарларны яулап алу өчен, бизнесның мотивациясе булырга тиеш. Шул юк икән, товар да юк. Түрәләрнең эше – менә шул мотивацияне үстерә торган туфрак әзерләү. Туфрак бар икән, бизнес орлыгын да чәчә, җимешен дә җыя аның. «Ни өчен без чит ил товарларына шулкадәр беректек?» дигән сорауның исә җавабы бер генә: үзебезнекен җитештерүгә караганда, импорт кайтару икътисади яктан отышлырак. Табышның чыпчык тезеннән булып, түлисе салымың муеннан булса, нидер җитештерүне көйгә салу мөмкин түгел ул. Үткән елларда бюджет профицитлы булды югыйсә. Чимал саткан акчаны да, бюджет җыйган салымнарны да чикнең теге ягына аударып тордык һәм… ярык тагарак янында калдык. Салымнарны киметеп, үзебезнең җитештерүчеләргә юл ачарга теләүчеләр булмады. Хәзер акча да юк, үзебезнең товар да.

pixabay.com

Башка илләр алай эшләми. Максат куйганнар икән, аңа ирешәләр. Онытмыйлар. «Бөек ефәк юлы» дигән проект бар иде бит әле. Кытайдан Европага товарны Россия аша ташырга тиешләр иде. Бу Кытай өчен дә, Россия өчен дә, Европа өчен дә отышлы проект булачак иде. Йөк ташу тегеләргә арзанга төшә, безнең тимер юллардан үткән саен, составлардан исә валюта тамып кала. Меңнәрчә чакрымнар тамып баргач, бик күп җыела ул. «Бөек ефәк юлы» 2014 елда юнәлешен үзгәртте, Россияне әйләнеп үтәргә дигән максат куйды. Алай кыенрак, әмма ышанычлы дигән фикергә килделәр Көнчыгыштa да, Көнбатышта да. Һәм менә Кытайның Xinhua агентлыгы хәбәр итә: Күк асты иленнән Германиягә, Россияне әйләнеп үтеп, йөк поезды йөри башлаган. Сиань – Мангейм маршруты буенча беренче поезд 13 апрельдә кузгалып киткән. Xinhua яза: «Маршрут, – ди, – Кытай өчен дә, башка илләр предприятиеләре өчен дә яңа халыкара базарлар ача». Без савасы табышны Казахстан, Азәрбайҗан, Румыния, Венгрия, Словакия һәм Чехия чумырып алачак дигән сүз бу. Без исә авыз ачып калганбыз, русча әйтсәк, прозевали. Кытай – безгә дус инде ул дуслыкка, әмма чин йөк ташучылары Россия аша транзитны «товар өчен хәвефләнү» дигән сәбәп белән туктаталар. Санкцияләр менә шулай эшли ул: Россия аша поезд йөртү дә бизнес өчен куркынычка әйләнә.

Болай яшәсәк, без углеводород базарларыннан да колак кагачакбыз. Ул базарларны яулау өчен, россияле чиновниклар тырышмаган түгел, тырышканнар. Менә дигән ат йөрешләре ясалган. Гыйбри порталы яза: Германиядә Мануэла Швезиг дигән алманы сәясәтче ханымның эшен тикшерәләр. Ул Россия тарафыннан мул финансланган экологик фонд оештырган. Нечкәлекләрен шәрехләп тормыйбыз инде, озакка китә. Шул фонд тырышлыгы белән «Төньяк агым – 2» проектын уңышлы тормышка ашырырга юллар ачылган. Бик күп миллиардлар тыгылган ул «агым» белән нәрсәләр булуын беләсездер инде? Ул миллиардларны үзебездә ипи пешерү заводлары өчен җиһазлар җитештерүгә, медицина пирчаткәләре ясауга тыксак, яхшырак буласы булган икән дә бит. Россия үсендергән экологлар тырышлыгы белән европалылар үз газларын чыгару проектларыннан баш тартканнар. Газның бик бай ятмалары Алманиядә дә, Польшада да бар ул, әмма аларны чыгару, чынлап та, табигать өчен зыянлы. Хәзер Дания, вакытлыча гына булса да, үз газын чыгаруны арттырып, Россиянекеннән баш тартырга җыена. Греция, үз ятмаларыбыздан газ чыгарачакбыз, дип шаулый. Туңа башласалар, немецлар белән поляклар да үз сланец катламнарын борауламый калмас. Әлегә алар Якын Көнчыгыш һәм Африка илләрен зәңгәр ягулык чыгаруны арттырырга дәртләндерәләр.

Эшләр менә шулайрак тора. Дөнья икътисадының һәм сәясәтенең шахмат тактасында диспозицияләр бер дә безнең файдага түгел. Менә шулардан чыгып, язма исемендәге сорауга бераз җавап бирдек шикелле. Латинча «Necessitas auctum intellectum» дигән гыйбарә бар, русчага аударсак, «Необходимость обостряет разум» буларак яңгырый. Безгә менә шуңа өметләнергә генә кала: катлаулы һәм авыр шартларда талантларның ачылуына.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Зөһрә
САДЫЙКОВА

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

«ВТ» архивыннан

ҖИРГӘ ТӨШҮ

Бәрәңгесез булмый!

Татарстан бакчачылар берлеге башлыгы Владимир Дейнекин фикеренчә, быел бакчачылар саны артмаган очракта да, тәгаен кимемәячәк.

– Бер көнне телевидениедә «Сез май елларын ничек уздырырга җыенасыз?» дигән темага сораштыру оештырганнар иде. Респондентларның 75 проценты бу көннәрне эшләп уздырачакларын белдерде. Димәк, бу – кешеләр я авылга кайтачак, я бакчаларга барачак дигән сүз инде. Үзегез карагыз: кәбестә бәясе ничек күтәрелде бит. Гаҗәп! Шуңа күрә мин быел бакчада эшләргә теләүчеләр артыр дип уйлыйм, – ди республиканың баш бакчачысы.

Соңгы елларда авылларда бәрәңге утыртучылар да кимегән иде. Авыл халкы әйтүенчә, быел аннан башка булмый. Моңа кадәр буш яткан участокларга да бәрәңге утыртырга ниятләп торучылар бар. Питрәч районының Керәшен Сәрдәсе авыл советы башлыгы Николай Морозов сүзләренә караганда да, быел авылдашлары бәрәңгене күпләп утыртырга җыена.

– Бездә халык болай да бәрәңгедән өзелми. Тик быел, илдәге вазгыятьтән чыгып һәм халыкның сөйләшүеннән аңлашылганча, мәйданнарны арттырырга теләүчеләр шактый. Мәсәлән, үземнең дә унбиш сутый җирем бар иде. Быел буш яткан бакчаларга малларга азык чөгендере һәм кабак утыртачакмын. Халыкның күпчелегендә орлыклык бәрәңге юк иде. Каяндыр эзләп йөрмәсеннәр, уңайлы булсын дип, авылга сыйфатлы симәнә алып кайтырга булдык. Бер килограммын 45 сумнан тәкъдим итәләр. Халык өчен шулай ук яхшы булыр, – ди ул.

Николай Морозов әйтүенчә, авылларында буш торган участоклар да бар.

– Авылда сатуга куелган уннан артык участок бар. Быел икесен карап киттеләр. Җирләр кипкәч, кайтырга ниятләп торалар. Шәһәрдән кайтучыларга, беренче чиратта, яшелчә утыртыр өчен бакча кирәк, – ди ул.

Арча районының Иске Кырлай авылында яшәүче Фәйрүзә Әхмәтҗанова утыртасы бәрәңгеләрен баздан чыгарып әзерләп куйган инде.

– Быел бәрәңге бик яхшы сакланган. Шулкадәр матур, – диде ул, сөенеп. – «Кырлай» агрофирмасы яшелчәчелек белән шөгыльләнгәч, бездә аңа кытлык юк, бер елны да тилмергәнебез булмады. Үзебез дә гомергә бакчаларда икенче икмәк утырттык. Ләкин башка елларны: «Бар бит инде ул. Артыгы нәрсәгә?» – дип кенә карый идек. Быел ике бакча утыртырга ниятләп торабыз. Башкача булмый. Яшелчәсен дә, бәрәңгесен дә утыртасы инде. Дөнья хәлен белеп булмый. Авылдашларым да минем фикердә тора. Халык белән аралашып яшибез бит. Үзебездән артса, терлегенә дә, кошкортына да кирәк. Бәрәңгесез берничек тә булмый хәзер!

Аның әйтүенчә, авылларына кайтып төпләнүчеләр күп булмаса да, бар. Әле күптән түгел генә шундый бер гаилә күченеп кайткан. «Бакчаларны карыйбыз. Яшелчә утыртабыз, дип кайтканнар алар да», – ди Фәйрүзә Әхмәтҗанова.

Бу атнада Әлки районына сәфәр кылган идек. Халыктан бәрәңге утырту-утыртмау турында да сорадык. Сөйләшкән берсе бәрәңгесез яшәп булмавын әйтте. Тик узган ел уңыш начар булу сәбәпле, күпләрдә орлыклык бәрәңге юк икән. Андыйлар туганнарыннан, авылдашларыннан алып утыртмакчы була. Симәнәләрен алыштырырга җыенучылар исә Түбән Кама районындагы фермер хуҗалыгыннан алып кайтмакчылар икән. Орлыклык бәрәңгене Түбән Әлки авылы кибетендә дә саталар иде. Сатучы аны Чувашия республикасыннан кайтартуын әйтте.

– Килограммын 40 сумнан сатабыз. Әле кичә генә алып кайттык. Моңа кадәр алып кайтканыбыз булмады. Халык алырмы, юкмы – әлегә әйтеп булмый, – диде кибетче.

Биектау районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге башлыгы Зөһрә Гарифуллина әйтүенчә, әлегә бәрәңге утырту темасы икенче планга калган. Чөнки халык су басудан иза чиккән икән быел.

– Башка елларны бу кадәрле үк булмый торган иде, быел авырга туры килде. Газ казаны булмәсенә су үтеп, бер атна инде җылылыксыз утырам, – диде ул. Шуннан соң бәрәңге темасына күчеп, менә мондый фикерен җиткерде: – Соңгы елларда бәрәңге утыртучылар бездә дә кимеде. Икенче икмәкне башка төрле яшелчәләр алыштырды. Авыл халкы да сәламәт туклануга күчеп бетте. Шулай да, быел үзебез үстерәсе булыр, ахры, дип әйтүчеләр бар. Ләкин әлегә өстәмә җирләр сорап килгән кешеләр күренми. Бәрәңгене үстерү генә түгел бит әле. Аны саклыйсы да бар. Су төшкәч, идән астына куя торган түгел. Халык, җаен табып, сарай кебек җирләрдә саклый бәрәңгене.

Аның сүзләренчә, Алан-Бәксәр авыл җирлегенә яшәргә кайтучылар күп.

– Бездә, чыннан да, җәен шәһәрдән кеше күп кайта. Ләкин аларның күпчелеге әти-әнисеннән, туганыннан калган йортта яши. Кайсы төзәтә, яңарта, кайсы ул участокка яңа йорт тергезә. Андыйлар – бик оста бакчачылар да. Берничә теплица куеп, ни генә үстермиләр. Шуңа күрә ташландык булып яткан бер генә участок та юк бездә, – ди ул.

Дача бәяләре күтәреләчәк

Авылларга гадәттә әти-әнисеннән, туганыннан калган йорты булганнар кайтып урнаша. Гомер буе калада яшәп, пенсиягә чыккач, авылга кайтып төпләнүчеләр дә шактый. Андыйлар турында үзебез дә әледән-әле язып торабыз. Тик барлык кеше дә, шәһәрдәге фатирын калдырып, салага китәргә риза түгел. Андыйлар исә башка юлларны эзли: я шәһәр янында дача сатып ала, яки аны арендага алу җаен карый.

Риелтор Айгөл Җәләева сүзләренчә, дача сатып алучыларны ике төркемгә бүлеп карарга мөмкин. Аларның беренчесе шәһәр янындагы участокларны бары тик барып ял итү урыны итеп кенә караса, икенчесе исә үз яшелчәсен үстерер, ягъни җирдә эшләр өчен файдалана. Быел соңгылары тагын да артырга мөмкин, ди ул.

ГАЗЕТАНЫҢ ҺӘМ АВТОРНЫҢ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРЕНДӘ УЗДЫРГАН СОРАШТЫРУ НӘТИҖӘЛӘРЕ	
Бәрәңге бакчасын быел арттырырга җыенам	146
Булганы җитәр	315
Сатып алырбыз әле	29
Ул турыда уйлаган юк	28

Сораштыруда барлыгы 518 кеше катнашты.

– Ел саен, яз җитүгә, дача участоклары белән кызыксынучылар артуны күзәтәбез, – ди ул. – Быел да шулай булыр, ләкин кешеләр хәзер кыйммәт булмаган участокларга өстенлек бирә. Ипотека бәяләре өскә үрмәләү сәбәпле, халык кулында булган акчаны кулланып калырга омтыла. Җир кишәрлекләре бәяләре андагы уңайлыклардан, урнашу урыныннан чыгып бәяләнә. Казанда алар 300 мең сумнан башлана. Шулай ук җир кишәрлеген 2,5 млн сумга да тәкъдим итүчеләр бар. Ә дача бәяләре 20 млн сумга кадәр җитә.

Ә менә дачаларны арендалауга килгәндә, риелтор фаразлавынча, быел бу юнәлеш буенча, чыннан да, ыгы-зыгы артыр.

– Чит илләр белән вазгыять аңлаешсыз. Алга таба ни буласын әйтеп булмый. Шуңа күрә халык быел җәйге отпускларын Россия эчендә генә үткәрер шикелле. Шәһәр халкы инде бүгеннән сезон буена дачалар арендалау турында уйлый башлады. Бу, әлбәттә, бәяләрне дә күтәрәчәк, – ди ул.

Без дә берничә төрле игъланнар сайтларын карап чыктык. Чыннан да, бер айга яки бер сезонга арендага биреп торучылар шактый күп икән. Бер айга дачаны арендага алу бәясе 10 мең сумнан алып 50 мең сумга кадәр җитә. Дөрес, аена 100 мең сум сораучылар да бар. Мәсәлән, Лаеш районының Матюшино авылындагы йортны әнә шундый хакка тәкъдим итәләр. «Авыл – шәһәрдән 23 чакрым ераклыкта. Йорт Идел елгасының беренче линиясендә урнашкан. Йорттан пляжга 10 метр гына барасы. Мунчасы юк. Йортны кечкенә балалары булган гаиләгә яки өлкән парларга гына бирәм», – дип язылган игъланда.

Казанда яшәүче Илдус Әхмәтов та быел арендага алыр өчен дача участогы эзли.

– Казан тирәсендә җәй айлары өчен дача арендалау турында моңа кадәр дә уйланганыбыз бар иде. Ләкин тәвәккәлләп караганыбыз булмады. Хатыным Чистай районыннан минем. Узган елларда җәен һәрвакыт шунда кайтып йөрдек. Ләкин ара бик якын түгел, атна саен кайтып йөрү арыта. Шуңа күрә быел йорты, мунчасы һәм зур булмаган бакчасы булган дача карарга уйладык. Игълан да бирдем. Дачаны 1 майдан алып 1 октябрьгә кадәр арендалар идек. Быел яшелчә бәяләре бик нык кыйммәтләнде. Үзем дә, хатыным да эштән курка торган кешеләр түгел. Балаларга да эш тияр бераз. Участокта яшелчәләр үстерербез дип торабыз. Хәтта бәрәңге утырту уе да бар. Эш атнасыннан соң шашлык пешереп, мунча ягып, ял да итәрбез. Кыскасы, планнар зурдан безнең. Ялы да, эше дә бергә булыр дип өметләнәбез, – диде Илдус Әхмәтов.

Укучы сүзе

Гүзәл Смирнова: «Халык авылларда, котырып, бәрәңгене күп итеп утыртырга җыена. Мөгаен, бәясе очсызланыр. Мин бәрәңге җирен киметергә уйлап торам әле. Җитмәсә, сатып алырга кибеттә булыр. Быел да авылга сирәк кайтылды кыш көне, кибетнекен дә рәхәтләнеп ашадык».

Гөлсинә Хәсәнова: «Ел саен утыртыла торган җир малга да, үзебезгә дә җитә».

Сәрия Мукминова: «Бакчабыз Аллаһка шөкер. Кая тагын зурайтырга? Үзебезгә дә, балаларга да җитә, сатарга да кала әле. Ходайның биргәненә мең шөкер».

Халисә Уразова: «Ел саен бәрәңге утыртырга Нурания апа янына кайтам. Эшкәртергә, казып алырга, чокырга салырга да булышам. Бакчасы әйбәт апаның, йомшак, ел да кул белән утыртабыз. Бөтенебезгә дә җитә, аның балаларына да, безгә дә! Бәрәңге күп китми үзе, бер-ике капчык була микән. Гадәттә бакчалары кипкәч утыртабыз инде».

Гәүһәрия Хуҗина: «Бер елда шулай бәрәңге уңмыйча, сорау күп булса, икенче елда уңа ул, Алла боерса. Кая куярга белмичә аптыраган чаклар да булды. Элеккеге кебек хәзерләүләр конторасы (заготконтора) юк җыярга. Елы уңышлы килсә, вакытында яңгыры, җылысы, илләрдә тынычлыгы булса, калганы бар да булыр».

Сәгъбҗан Әбҗәлетдинов: «Безнең гаиләгә бәрәңгене сатып алу отышлы. Бер уңыштан икенчесенә кадәр 6–7 чиләк бәрәңге җитә».

(Газетаның «ВКонтакте» сәхифәсендә калдырылган фикерләр)

Күзгә укуны яздан ук кайгырталар. Буа районының Яңа Чәчкап авылында яшәүче әти-әниләр мәктәп язмышы өчен борчыла. Киләсе елдан ул тугызъеллыкка калырга мөмкин. Алар безгә, мәктәпкә тимәсеннәр иде, дип хат язган. Заманында миллион сумлык грантлар откан, даны республикага таралган мәктәпне саклап калып булырмы?

быел тагын бер. Дүрт ел бала тапмаганнар дигән сүз. 39лап укучыга – 20ләп хезмәткәр. Күрше авылдан элек җәяү йөрсәләр, хәзер укучыларны автобус йөртә. Мәктәп ярыйсы гына чыгымлы дип әйтәсем килә. Илнең икътисади авыр булган заманда, мәктәпләрне саклагыз, дип ялкынланып сөйли алмыйм. 39 бала белән мәктәпне саклау авыррак дип уйлыйм. Авылда калыгыз, дип кенә булмый. Кул хезмәте кими, техника заманы, авыл халкына эш юк. Мәктәпнең язмышы кызганыч. Авылда ферма, мастерскойлар ябылгач, бинала ишелеп бетте. Әлбәттә, мәктәпнең киләчәген мондый хәлдә күрәсе килми.

Сәрия МИФТАХОВА

БАЛА ТУМАСА, БӘЛА ТУА

УКУЧЫЛАР БУЛМАУ СӘБӘПЛЕ, МӘКТӘПЛӘР КЫСКАРА

Кагылмагыз мәктәпкә!

«Яңа Чәчкап урта мәктәбе – татар мәктәбе. Балалар туган телдә белем ала. Күп еллар дәвамында ул якын-тирә авыллар тормышының үзәге булып тора. 25 чакрым радиуста бердәнбер урта мәктәп. 10–11 нче сыйныфка балалар Бик-Үти, Кайбыч, Әлки авылларыннан укырга килә. Күпбалалы гаиләләр һәм балаларны опекунлыкка алган гаиләләр күп. Бездә БДИны тапшыра алмаучылар юк. Узган ел ике укучы рус теленнән – 82, бер укучы химиядән 96 балл җыйды. Барлык укучылар да сынауларны уңышлы тапшырып, югары уку йортларына керә. Узган ел мәктәпне 7 укучы тәмамлаган иде. Аларның өчесе – КФУга, икесе – медицина университетына, берәр бала КДЭУ һәм аграр университетка укырга керде. Без, әти-әниләр буларак, балаларыбызның татар мәктәбендә белем алуы белән горурланабыз. 10–11 нче сыйныфта да укуларын шушы мәктәптә дәвам иттерүләрен телибез. Сездән мәктәпкә урта мәктәп статусын саклап калырга ярдәм итүегезне үтенәбез», – дип яза әти-әниләр.

2002 елда төзелгән 265 урынга исәпләнгән якты һәм җылы мәктәп бу. Янгын сигнализациясе, видеокүзәтү җайланмалары урнаштырылган. Дәресләр өчен кирәкле җиһазлар, методик кулланмалар җитә. Китапханәсе, музее, спорт залы, ашханәсе бар. Ашханәгә 2021 елның җәендә капиталь ремонт ясалган. Җәйге чорда мәктәп базасында сәламәтләндерү лагере эшли. Тәрбия туган телне, милли гореф-гадәтләрне, татар халкының гореф-гадәтләрен саклауга юнәлдерелгән. Ел саен мәктәптә язучы Әхмәт Рәшит исемендәге фәнни-гамәли конференция үткәрелә. Анда быел төрле районнардан 150ләп укучы катнашкан. Конференциягә язучылар, Казан дәүләт аграр университеты, Казан федераль университеты галимнәре килә. Мәктәптә 4 ел рәттән гран-при алган «Нур» театр төркеме эшли.

«Тынычлап укыйсы килә»

Авылда 400дән артык кеше яши. 230лап хуҗалык бар, шуның 80ендә тормыйлар. Моңа кадәр бакчага ике бала йөргән. Сабыйлар аз булгач, анысы да ябылган. Хәзер алар дәү әниләре белән өйдә утыра. Мәктәптә барлыгы 39 бала белем ала. Шуларның икесе – Зәринә белән Әдилә 10 нчы сыйныфта укый. Быел 9 нчы сыйныфта бер бала да юк.

Мәктәп директоры Рөстәм Бикмуллин әйтүенчә, мәктәпнең язмышы өчен барысы да борчыла. Балалар саны аз булгач, әллә нигә өмет итеп тә булмый. Быел 1 нче сыйныфка бер укучы киләчәк. Иске мәктәптә 450 укучы белем алган. Тик авылда эш булмагач, яшьләр шәһәргә китә.

– Соңгы елларда 57 бала иде, хәзер әкренләп кими. Урта мәктәп булып саклану өчен 50дән күбрәк укучы кирәк. Анысын да яхшы аңлыйбыз. Тик бер елга сабыр итмәсләрме дип өметләнгән идек. Быел 10 нчы сыйныфта укучы кызларга мәктәпне үзебездә тәмамларга мөмкинлек тудырылсын иде. Район методистлары мәктәп саклана дигәч, шуңа ышанып калганнар иде, – ди Рөстәм Бикмуллин.

10 нчы сыйныфта укучы кызларның әти-әниләре белән дә сөйләштек. Зәринә белән Алинә икесе дә – укытучы кызлары, отличниклар. Алар укытучы, табиб булырга хыялланa.

– Мин гаиләдә – төпчек бала. Авыл бетмәсен дип, шәһәргә китмәдем. Колхозда механизатор булып эшләдем. Мәктәп ябылса, авыл да юкка чыгачак бит. Кызларыбызның җаваплы чоры. Бик ныклап имтиханга әзерләнәләр. Чит мәктәпкә җибәрмичә, үзебезнекендә укып бетерсеннәр иде инде. Ни тугыз түгел, ни унбер түгел бит, – ди ике бала атасы Наил Сәмигуллин.

Салих Шәрәфетдинов та шундый ук фикердә, ул да Әдилә өчен борчыла.

– Узган ел 9 нчы сыйныфны 7 бала тәмамлады. Шуларның бишесе техникумга китте. Әдилә белән Зәринә унынчыга калды. Иптәшләре киткәндә, аларның да китәсе килде. Тик мәктәп саклансын дип, калырга үгетләдек. Әгәр 10–11 нче сыйныфка калдырсак, мәктәп ябылмыймы, дип сорадык. Уңай җавап ишеттек. Киләсе елдан мәктәпне кыскартып, балаларны Буага укырга җибәрмәкчеләр. Район бездән 20 чакрым тирәсе. Балаларның ярты елы икенче мәктәпкә ияләшеп үтәчәк. Әдиләнең читкә китәсе килми. Монда – үз укытучылары. Балаларга стресс булмасын иде инде. Тагын бер ел укып, тынычлап имтиханнар биреп, теләгән уку йортларына керсеннәр иде, – диде Салих Шәрәфетдинов.

Даны еракларга таралган

Зөфәр Сәлахов әлеге мәктәптә 13 ел директор булып эшләгән. 73 яшьтә булса да, мәктәптә физика, математика, астрономия фәннәрен укыта, өстәвенә Буа медицина училищесы студентларына белем бирергә дә өлгерә. Заманында Яңа Чәчкап мәктәбе ике ел рәттән миллион сум откан. Әлегә акчага республикада иң зур телескоп, электрон микроскоп, химия, физика кабинетларына җиһазлар сатып алганнар. Дүрт укытучылары Мәскәүдә укып кайткан. Укучыларын хәтта астрономиядән халыкара бәйгеләргә чакырганнар. Физикадан республикада җиңүче булганнар. Уңышларны санасаң, аз түгел.

– Физика, астрономиядән көчле укучылар, көрәшчеләр бар. Театр гран-при алды, – дип, хәзерге уңышларны барлады Зөфәр Сәлахов. – Балалар саны аз, артмый инде ул. 2018 елда бер бала туса,

«Авырткан урын бу»

Мәктәпне саклап калып буламы? Бу хакта Буа районы башлыгы Ранис Камәртдиновның фикерен белештек.

– Бездән генә тормый бит ул, – ди башлык. – Бала саны азая башлагач, мәктәпнең чыгымнарын Финанс министрлыгы санап чыгара. Авылда кечкенә мәктәпне тоту чыгымнар сорый. Без үзебез дә ябуга, кыскартуга каршы. Авырткан урын бу. Без, бөтенләй япмас өчен, урта мәктәпне – тугызъеллыкка, тугызъеллыкны башлангычка калдырабыз. Чама калмагач, башлангычны ябып, күрше авылларга йөртәбез. Киләсе елда районда 4 мәктәп кыскарачак. Миңа әти-әниләр риза дип әйттеләр. Кыскартуга бөтенләй каршы килмичә калган кеше булмый. Кем булса да каршы чыга. Әти-әниләр аңлап җиткермиләр: балаларга ярышып уку өчен көндәшлек кирәк. Кичә генә Ташкичү авылына барып кайттым, анда мәктәптә ремонт бара. Бер зур бүлмәдә биш бала утырган. Икесе – 1 нче, өчесе – 3 нче сыйныф укучылары. Ике сыйныфны кушып укытканда, нинди көндәшлек булсын? Балалар бер-берсе белән аралашырга, җәмгыятькә җайлашырга тиеш. Унынчы сыйныфта ике бала укып, нәрсә була инде? Мәктәп кыскартылмый дип берәү дә вәгъдә итә алмый. Иртәгә нинди көн буласын мин дә, мәгариф идарәсе дә әйтә алмый. Начар булмаячак, моның өчен борчылырга кирәкми. БДИга да әзерләнерләр. Безнең укытучыларның 15 проценты – пенсия яшендә. Информатика, математика, физика, химия укытучылары җитми. Бер укытучы берничә фәнне алып барырга мәҗбүр. Ул рус телен, тарихны, җәмгыять белемен, физиканы, биологияне дә укыта. Буага килү яхшырак булачак. Шартлар да бар. 11 нче сыйныфны тәмамлагач, вузларга керәләр. Районда бер-берсе белән аралашырга, ияләшергә җайлырак. Сәләтле балалар мәктәбенә авыллардан да киләләр. 30лап укучы интернатта яши. Балалар саны артса, кабат ачарбыз. Мин – оптимист. Мондый вазгыятьтә халык авылларга күбрәк кайта башлар, дип уйлыйм. Халык кайтса, авыллар урамында да бәйрәм булыр.

Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгының матбугат үзәге:

– Без бер мәктәпне дә япмыйбыз һәм кыскарту турында бернинди күрсәтмә дә бирмәдек. 2012 елның 29 декабрендә гамәлгә куелган «РФдә Мәгариф турында»гы 273 нче Федераль законның 9 нчы маддәсе нигезендә, муниципаль белем бирү оешмаларын булдыру, үзгәртеп оештыру, ябу районнарның вәкаләтенә керә. Буа районының Яңа Чәчкап урта мәктәбе филиалын гамәлгә куючы – Буа районы Башкарма комитеты. Буа районы мәгариф идарәсе мәгълүматларына караганда, 2021–2022 елгы уку елында әлеге мәктәптә 39 бала укый. Шуларның 4есе – 10–11 сыйныф укучылары. Киләсе уку елында 38 укучы белем алыр дип планлаштырыла. Балаларга 15 укытучы һәм 1 башка мәктәпләргә йөреп укытучы (внешний совместитель) белем бирә. Укытучыларның уртача яше – 50. Киләсе уку елында 10 нчы сыйныфта укучы булмаячак. Быелгы уку елында да 9 нчы сыйныф буш. 11 нче сыйныфтагы ике укучыга Буа шәһәренең Сәләтле балалар өчен мәктәп-интернатында уку һәм яшәү мөмкинлеге биреләчәк.

АКЧА ТҮЛӘП ӘЙТЕР СҮЗЛӘРЕМ БАР...

Соңгы арада күпләрнең юлдашына әверелеп баручы психологларның көндәшләре барлыкка килгән. Бушлай белдерү сайтларында бер сәгатькә дус, сердәш булырга тәкъдим итүчеләр пәйда булган. Кыска вакыт эчендә алар популярлык та казанырга өлгергән. Әйтик, барыбызга яхшы таныш «Авито» порталында соңгы өч айда алар белән кызыксынучылар өч тапкыр арткан.

Сер сөйләргә, эчеңне бушатырга якын кешең булмаса яки сине аңлаучы табылмаса, телефон номерын җыясың да трубканы алган кеше синең моң-зарыңны күпме кирәк шулкадәр тыңлаячак. Акчаң гына булсын! Кешенең эч серләрен тыңлауның ярты сәгате 500 сумнан башлана. Араларында бу вакыт эчендә сиңа 300 сумга дус булып торырга ризалар да бар. Аралашу бер сәгатькә сузылса, 1000–1500 сум акчаңны чыгарып салырга туры киләчәк.

«Авито» порталы белгечләре моның өше игъланнарның пандемия чорында ук күренә башлаганлыгын әйтә. Әмма ул вакытта бу хезмәт алай ук популярлашып китә алмаган. Бүген исә сердәшләр кирәк.

Белдерүләр тактасында урын алган шундый бер сәгатьлек «дуслар» белән без дә элемтәгә кереп карарга булдык. Иң беренче очраган белдерүдә күрсәтелгән номерны җыям. Үзен Люция дип таныштырган ахирәткә ике тапкыр шалтыраткач кына эләгә алдым. Трубкада ягымлы тавыш ишетермен дигән өметләрем акланмады. Телефон аша бер сәгатьлек дусларның ниндирәк булуын күзаллау өчен, сөйләшүебезне үзгәртмичә бирәм.

– Алло, Люция? Исәнмесез!

– Тыңлыйм *(коры гына).*

– Белдерү буенча шалтырата идем.

– Шуннан? *(Тавыш дигәнең бу сүздән соң да йомшармады).*

– Бер сәгатькә дус булам дип игълан калдырган кеше сез буласыздыр бит?

– Әйе *(шундый ук коры тон белән). Пауза.*

– Сезнең белән теләсә нинди темага сөйләшергә буламы?

– Була. Мин телефоннан гына эшлим. Сәгате 500 сум. Син сөйлисең – мин тыңлыйм. Җинаятьтән кала, теләсә нәрсә турында сөйләшә алабыз.

– Нинди җинаять?

– Үзегез кылган берәр җинаять турында сөйләп атсагыз, полициягә хәбәр итәсе булачак. Миңа проблемалар кирәкми *(шаркылдап көлеп җибәрде).*

– Әәә... Сез үзегез кем булып эшлисез соң?

– Көнкүреш кибетендә консультант, – диде ул, гадәттәгечә коры гына.

Соңрак шалтыратырга вәгъдә биреп, тизрәк трубканы куйдым. Люция «дускай» белән сөйләшкәч, күңелдә шулкадәр авыр хис калды. Аңа эч серемне бушату түгел, йомышым төшсә дә башка шалтыратмас идем, билләһи. Люциянең кибеткә килгән халык белән ничек аралашуы гына кызык.

Диплом кирәкми

Роберт исемле ахирәт белән шунда ук уртак тел таптык. Трубканы алгач ук, көр тавыш белән, күптән аралашмаган дусты шалтыратканга сөенгән кешедәй сөйләшә башлады ул. Ни өчен шалтыратуыңны, нинди темага сөйләшәсе килгәнне дә сорап тормады. «Ничек хәлләр? Ни эшләр бетерә идең әле?» – дип сораулы ул якын танышлар кебек. Баш авырттан башлап, әле язылып да башламаган мәкаләгә кадәр барысын да сөйләшеп чыктык. Газетадан икәнемне белгәч, сөйләшәсе килмәс дип шикләнгән идем. Аңа да исе китмәде. «Бер оешмада машина йөртүче булып эшлим. Буш вакытта шулай акча эшлим. Аралашырга яратам. Кеше белән уртак телне тиз табам», – ди ул.

«ВТ» архивыннан

Робертның телефон аша дус була башлавына әле ярты гына ел икән. Мондый хезмәткә сораучың зур булуын бүген иң якын кешеләрнең дә бер-берсен аңламавы, әллә никадәр кеше арасында яшәп тә, үзен ялгыз хис иткән кешеләрнең күп булуында күрә ул.

– Миңа шалтыраткан һәр ике кешенең берсе сүзен «мине аңламыйлар» дип башлый. Аралаша торгач, ялгызлык, бала тәрбияләү, депрессия, армиядән кайткач ташлаган егетләр, каргыш, бозым – кыскасы, нәрсәләр турында гына сөйләшмибез. Конкрет сорау белән шалтыратучылар да бар. Әйтик, бервакыт бер кыз шалтыратып, ир-ат буларак хатын-кыз хыянәтенә мөнәсәбәтемне сорады, – ди Роберт. – Бу эштә дипломлы белгеч булырга кирәкми. Иң мөһиме – кешене тыңлый, юата, үсендерә белергә кирәк. Тормыш тәҗрибәм зур булмаса да, һәр нәрсәгә үз фикерем бар. Күп очракта әнә шуңа һәм мантыйкка таянам.

Сер тыңлаучы Робертның ярты сәгатьлек дуслыгы 700 сумнан башлана. Бергәләп кая да булса барып кайтырга, күрешеп сөйләшергә чакырсалар, бу хак ике мәртәбә арта икән. Кафе, кинотеатр ише чыгымнарны да чакырган кеше үзе түли. «Бер кеше дә шалтыратмаган яисә рәттән өч-дүрт кеше белән сөйләшкән көннәр дә бар. Аена уртача 15000–17000 сум акча эшлим», – ди Роберт.

Үз хезмәтләре өчен иң түбән хакны (ярты сәгать аралашу – 200 сум) куйган белдерү хуҗасы белән дә элемтәгә кердем. КФУның психология факультетында укучы 21 яшьлек Алинә исемле кыз булып чыкты ул. «Безгә белем биргән бер тәҗрибәле психолог соңгы арада аңа мөрәҗәгать итүчеләр саны артуын сөйләгән иде. Халык бүген илдә барган хәлләрне аңлый алмыйча, андый чакта үз-үзен ничек тотарга белмичә аптырый. Минем күбрәк әнә шул кешеләргә ярдәм итәсем килә. Сәясәтне аңлап бетермәсәм дә, мондый чакта югалып калган кешегә булачак белгеч буларак психологик ярдәм күрсәтәсем килә», – ди ул. Шулай да әлегә Алинәгә нәкъ менә шушы сорау белән мөрәҗәгать итүчеләр бармак белән генә санарлык икән. «Бер сәгатьлек дуска мохтаҗ кешеләр, нигездә, ялгызлыктан зарланып, гаделсезлек, хыянәт h.б. турында сөйләшәсе килеп шалтырата», – ди ул.

Зыяны күбрәк

Казан дәүләт медицина университетының клиник психологы **Эльмира Миассарова** мондый җайлы «дуслар»га сагаеп карый. «Сезнең белән кем сөйләшеп утырмас? Бәлки, сез берәр мошенникка шалтыраткансыздыр? Хәлегезгә кергән булып, үзенә кирәкле мәгълүматны җыяр да төп башына утыртыр. Аннары мондый ясалма «дуслык»ның кеше психикасына да, файдасыннан бигрәк, зыяны күбрәк», – ди белгеч.

– Эльмира ханым, ни өчен соңгы арада күпләр бер сәгатьлек «дуслар» эзли башлады икән?

– Кеше белән авыр аралашкан, уртак тел таба белмәгән, ялгызлыктан тилмергән, ниндидер куркуларыннан арына алмаган кеше еш кына психологка мөрәҗәгать итә. Әмма соңгы арада килеп туган вазгыять яңа сәбәпләр китереп чыгарды. Бүген җәмгыятьтә киеренкелек, тискәре уй-фикерләр арту күзәтелә. Кешегә ярдәм сорап мөрәҗәгать итәрлек, бигрәк тә транспортта, кибеттә кешегә бер сүз әйтерлек түгел. Иплән кенә булышасы урынга, кызып китәргә, дорфа җавап кайтарырга гына торалар. Бүген хәтта бер гаилә булып, бер түбә астында яшәп ятучылар да бер-берсен аңламый. Ник дигәндә, илдә, дөньяда барган хәлләргә карашлары аерыла. Кемдер бу хәлләрне хуплый, кемдер кискен каршы. Нәтиҗәдә гаиләдә ызгыш, талаш, бер-береңне кимсетү кебек ямьсез күренешләр башлана. Шул рәвешле кеше үз уйларын, фикерләрен уртаклашыр кеше таба алмый интегә.

Психологка мөрәҗәгать итсәң, моңзарларың белән бүлешеп, эчеңне бушату белән генә чикләнә алмыйсың. Проблеманы хәл итү өчен, белгеч әйткәннәрне эшләргә, тырышырга туры киләчәк. Күпләр исә моңа риза түгел. Мәсьәләнең көч түкмичә, үзеннән-үзе җайлы гына хәл ителүен телиләр. Бер сәгатьлек «дус»ка исә эчеңне бушатасың да, вәссәлам. Ул тәнкыйтьләми, ниндидер авыр сораулар биреп аптыратмый, нәрсә дә булса эшләвеңне таләп итми. Алар поездда барганда танышкан юлдашны хәтерләтә. Син аны беренче һәм соңгы тапкыр күрәсен, шуңа күрә курыкмыйча эч серләреңне чишә аласың. Кешегә рәхәт булып китә, проблема да юкка чыккан кебек тоела. Әмма бу – вакытлыча рәхәтлек, үз-үзеңне алдау гына.

Кешенең гаджетлар колына әйләнеп, виртуаль аралашуга өстенлек бирүенә дә, нигездә, әнә шул җиңел юллар эзләве сәбәпче бит. Килеп туган вазгыятьтә кайбер социаль челтәрләргә керү чикләнде. Андагы җиңел аралашуга ияләнгән кеше хәзер моның башка юлларын эзли. Бер сәгатьлек «дуслар»га ихтыяҗ артуның тагын бер сәбәбе әнә шуннан гыйбарәт.

– Мондый «дуслык»ның нинди куркыныч ягы бар?

– Үз-үзеңне алдау, иллюзия бу. Бер белмәгән кешегә эч бушатып кына проблема хәл ителми бит. Ни өчен ул шуларны ук якын кешесенә, дустына сөйли алмый? Мондый хезмәтләр булганда кеше ул турыда уйланмый да, үзендә нәрсәнедер үзгәртергә тырышмый да, билгеле. Чүп кенә бәягә сине эһ тә итмичә тыңлаучы, аңлаучы булганда, нишләп артыгын селкенергә, тырышырга? «Бер сәгатьлек дус» хезмәтеннән файдаланган кеше әнә шундый буш уйлар белән яши башлый. Мондый күренешләр белән очрашкач, Япониядәге хәлләр бездә дә кабатлана күрмәсен, дип борчылам. Анда циклограмма рәвешендә виртуаль дус, ир, хатын сатып алып, шуның белән генә аралашып, көн күреп, чынлыкта ялгызың яшәү модага әйләнеп бара бит. Андыйларның гомере еш кына үз-үзенә кул салу белән тәмамлана. Эмоциональ бәйләнеш булмаган мондый мохиттә, иллюзиядә кеше озак яши алмый.

– Соңгы арада сезгә күбрәк нинди проблемалар белән мөрәҗәгать итәләр?

– Бүген кешене билгесезлек, иртәгәге көнгә ышаныч булмау куркыта. Безнең халык бүген яшәргә күнекмәгән. Хәзер моны, иртәгә тегене эшлим, акча җыям да фәлән әйберне алам дип планлаштырып яшәргә күнеккән без. Хәзер исә киләчәкнең нинди булачагы билгесез. Бүген кеше бездә дә сугыш башланмасмы, дефолт булмасмы дип борчыла. Шул рәвешле кешедә борчулы, хәвефле уйлар арта. Бу исә тора-бара депрессиягә үк китерергә мөмкин.

– Мондый шартларда ничек тынычлык сакларга?

– Вазгыятьнең үзгәрүе бездән генә тормый икән, тынычланасы гына кала. Монда инде контраст душ, мунча керү, саф һавада йөрү кебек гади генә әйберләрдән башлап, якыннарың белән күрешү, кунакларга йөрешү, яраткан эшең белән шөгыльләнү кебек бар нәрсә ярдәмгә киләчәк. Психолог буларак, аутотренинг серләренә дә төшенергә киңәш итәр идем. Ул гади генә алты күнегүдән тора. Алар кешенең эчке халәтен тулысынча җайга сала. Уй-фикерләр генә түгел, кан басымы, кәеф, йокы режимы да көйләнә. Читтән кемнеңдер килеп ярдәм иткәнен көтәргә кирәкми. Һәр кеше үз тормышы өчен үзе җаваплы. Моны аңлаган кешегә бернинди виртуаль дус та, буш хыяллар да кирәкми.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

25 апрель | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 15.30 «УЕННАН УЙМАК» 12+
10.00, 22.10 «МАЧЕХА» 12+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
11.30, 17.00 «Татарлар» 12+
12.00, 23.00 «СВОИ» 16+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа» 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 12+
14.45 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Уймак» һәм «Сәйлән» 0+
16.30 «Мин» 12+
17.30 «Татарстан без коррупции» 12+
19.00, 20.00 «Таяну ноктасы» 16+
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру» 12+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.45 «Каравай». Народное искусство в творчестве великого поэта 6+
00.15 «Таяну ноктасы» 16+
01.05 «Ком сәгате» 12+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Җырлыйк әле!» 6+
05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00, 21.5, 00.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05 «Галәм илчесеннән хәбәр бар». Габдулла Тукай турында телеочерк 6+
15.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
18.20 «Аклык турында җыр». Татарстанның халык артисты Зөһрә Сәхәбиева турында телеочерк 6+
19.10 «Татар халык җырлары». Җырлый Искәндәр Биктаһиров 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
22.20 «Аклык турында җыр». Татарстанның халык артисты Зөһрә Сәхәбиева турында телеочерк 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш…» 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
22.00 Премьера сезона. Сергей Марин, Игорь Петренко, Екатерина Вилкова в многосерийном фильме «НАЧАЛЬНИК РАЗВЕДКИ» (S) 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 К 70-летию Владислава Третьяка. Премьера. «Легенда номер 20» 12+
00.55 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Юлия Хлынина, Александр Балуев, Агриппина Стеклова, Алексей Агранович, Виктор Раков, Кирилл Кузнецов. «ЕЛИЗАВЕТА» 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
01.00 Ольга Будина. «ЗЕМСКИЙ ДОКТОР»

МАТЧ ТВ

06.00, 09.05, 12.30, 14.55, 17.50, 21.55 Новости
06.05, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.10, 12.35 Спец. репортаж 12+
09.30 «БОЕЦ БЕЗ ПРАВИЛ» 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
12.55 «Главная дорога» 16+
14.00 Классика бокса. Джо Фрейзер. Лучшее 16+
15.00 Пляжный волейбол. BetBoom Чемпионат России. Женщины. Финал. Прямая трансляция из Анапы
16.00 Пляжный волейбол. BetBoom Чемпионат России. Мужчины. Финал. Прямая трансляция из Анапы
17.00, 04.15 Футбол. Тинькофф Российская Премьер-лига. Обзор тура 0+
17.55 «Громко». Прямой эфир
18.55 Футбол. Тинькофф Российская Премьер-лига. «Краснодар» – «Зенит» . (Санкт-Петербург). Прямая трансляция
21.00 После футбола с Георгием Черданцевым
22.00 Профессиональный бокс. Г. Челохсаев – К. Маргарян. Прямая трансляция
00.30 Тотальный футбол 12+

НТВ

05.00 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.00 Сегодня
08.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. РУБЕЖИ РОДИНЫ» (S) 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 Премьера. «ПОЛИЦЕЙСКОЕ БРАТСТВО» (S) 16+
22.00, 23.30 Боевик «ПЁС» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.00 «Давай разведёмся!» 16+
10.00 «Тест на отцовство» 16+
12.15 «Понять. Простить» 16+
13.20 «Порча». «Ходок» 16+
13.50 «Знахарка» 16+
14.25 «Верну любимого» 16+
15.00 «МЕНЯ ЗОВУТ САША» 16+
19.00 «СУРРОГАТНАЯ МАТЬ» 16+
23.15 «ЖЕНСКИЙ ДОКТОР 3». 11-я и 12-я серии 16+
01.00 «Понять. Простить» 16+
01.50 «Порча» 16+

ЗВЕЗДА

05.10 «СМЕРТЬ ШПИОНАМ. ЛИСЬЯ НОРА» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 22.15 Новости дня 16+
09.25, 01.15 «ШТРАФНОЙ УДАР» 12+
11.20, 19.00 «Открытый эфир». Ток-шоу. Премьера! 16+
13.25, 14.05 «Крылья армии. История военно-транспортной авиации». Док. сериал. Фильм 1-й 16+
14.00 Военные новости 16+
14.20, 03.55 «ЦЕПЬ» 16+
18.45 «Спец. репортаж» 16+
20.40 «Война миров». Док. сериал. «Конница против танков» 16+
21.25 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Док. сериал. «Гарвардский проект. Психологическая война против СССР» 12+
22.30 «Между тем» 12+
22.55 «Скрытые угрозы». «Альманах №100» 16+

26 апрель | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «УЕННАН УЙМАК» 12+
10.00, 22.10 «МАЧЕХА» 12+
11.00 Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясен таршыру тантанасы. Турыдан-туры трансляция 0+
12.30, 16.30 «Татарлар» 12+
13.00 «И туган тел…» Бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның туууына 136 ел тулуга багышланган Шигърият бәйрәменнән турыдан-туры трансляция 0+
14.45, 05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Уймак» һәм «Сәйлән» 0+
16.00 «Родная земля» 12+
18.00 «Казаннан – казанга» 12+
19.00, 01.30 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Ватандашлар» 12+
23.00 «СВОИ» 16+
23.45 «Видеоспорт» 12+
00.10 «Соотечественники». Печали и радости Тукаева детства 12+
00.35 «Tatarstan Today. Открытый миру» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
08.00 «БЕР МӘХӘББӘТ, МЕҢ ФАРАЗ» 6+
08.40, 23.05, 04.15 «Җырлыйк әле!» 6+
09.40 «Туган җир» 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем» 12+
11.00 Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләген тапшыру тантанасыннан турыдан-туры трранcляция 6+
12.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
13.00 «И ТУГАН ТЕЛ…» Бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның туууына 136 ел тулуга багышланган Шигърият бәйрәменнән турыдан-туры трансляция 6+
15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
15.30 «Тамчы-шоу» 6+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
17.00, 00.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
18.20 Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләген тапшыру тантанасы 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
21.25 «И туган тел…» Бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның туууына 136 ел тулуга багышланган Шигърият бәйрәме 6+
22.20 Г.Тукай. «СӨЙ ГОМЕРНЕ!» Шигъри драма 6+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
22.00 «НАЧАЛЬНИК РАЗВЕДКИ». Многосерийный фильм (S) 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 «АнтиФейк» 16+
00.40 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Юлия Хлынина, Александр Балуев, Агриппина Стеклова, Алексей Агранович, Виктор Раков, Кирилл Кузнецов. «ЕЛИЗАВЕТА» 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
01.00 Ольга Будина. «ЗЕМСКИЙ ДОКТОР»

МАТЧ ТВ

06.00, 09.05, 12.30, 14.55, 21.40 Новости
06.05, 21.00, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.10, 12.35, 03.10 Спец. репортаж 12+
09.30 «НАЁМНИК: ОТПУЩЕНИЕ ГРЕХОВ» 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
12.55 «Главная дорога» 16+
13.55, 15.00 «МАТЧ» 16+
16.35 Хоккей. КХЛ. Кубок Гагарина. «Металлург» (Магнитогорск) – ЦСКА. Прямая трансляция
19.15 Баскетбол. Парибет Чемпионат России. Женщины. Премьер-лига. Финал. «Динамо» (Курск) – УГМК (Екатеринбург). Прямая трансляция
21.45 Футбол. Лига чемпионов. 1/2 финала. «Манчестер Сити» (Англия) – «Реал» (Мадрид, Испания). Прямая трансляция
00.50 «Есть тема!» 12+
01.10 Футбол. Кубок Либертадорес. «Эстудиантес» (Аргентина) – «Брагантино» (Бразилия). Прямая трансляция
03.25 Футбол. Кубок Либертадорес. «Коринтианс» (Бразилия) – «Бока Хуниорс» (Аргентина). Прямая трансляция
05.30 «Правила игры» 12+

НТВ

05.00 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.00 Сегодня
08.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. РУБЕЖИ РОДИНЫ» (S) 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 «ПОЛИЦЕЙСКОЕ БРАТСТВО» (S) 16+
22.00, 23.30 «ПЁС» (S) 16+
03.15 Их нравы 0+
03.30 «СТРАХОВЩИКИ» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.55 «Давай разведёмся!» 16+
09.55 «Тест на отцовство» 16+
12.10 «Понять. Простить» 16+
13.15 «Порча». «Медуза» 16+
13.45 «Знахарка» 16+
14.20 «Верну любимого» 16+
14.55 «ДОЛГИЙ СВЕТ МАЯКА» 16+
19.00 «КОМПАНЬОНКА» 16+
22.40 «ЖЕНСКИЙ ДОКТОР 3» 16+
00.30 «Понять. Простить» 16+
01.20 «Порча» 16+
01.45 «Знахарка» 16+
02.10 «Верну любимого» 16+
02.35 «Тест на отцовство» 16+

ЗВЕЗДА

05.20, 14.20, 03.55 «ЦЕПЬ» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 22.15 Новости дня 16+
09.25, 00.55 «МЕДОВЫЙ МЕСЯЦ» 12+
11.20, 19.00 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.25, 14.05 «Крылья армии. История военно-транспортной авиации». Док. сериал. Фильм 2-й 16+
14.00 Военные новости 16+
18.45 «Специальный репортаж» 16+
20.40 «Война миров». Док. сериал. «Кремлевские асы против Люфтваффе» 16+
21.25 «Улика из прошлого» 16+
22.30 «Между тем» 12+
22.55 «Легенды армии» с Александром Маршалом. Александр Бурда 12+
23.40 «УБИЙСТВО СВИДЕТЕЛЯ» 16+

ЙОЛДЫЗНАМӘ 25 АПРЕЛЬ – 1 МАЙ

КУЧКАР (21.03 – 20.04)
Коронавирустан соң сәламәтлекнең, ниһаять, әйбәт үк ныгуы эш нәтиҗәсендә шундук сизелер. Бик кирәкле көнкүреш техникасын отышлы гына бәядән сатып алу мөмкинлеге чыгар. Якыннарыгыз яхшы хәбәр белән сөендерер.

ҮГЕЗБОЗАУ (21.04 – 20.05)
Бу чорда башыгызга кыю фикерләр килер. Аларны, һич шикләнмичә, гамәлгә дә ашыра башларсыз. Җыеп кына әйткәндә, уңай яңалыкларга, шатлыклы вакыйгаларга гаять бай атна.

ИГЕЗӘКЛӘР (21.05 – 21.06)
Атна башында, ыгы-зыгыдан, шау-шудан туеп, тынычлыкта ял итеп алу теләге туар. Үзегезне рухи яктан камилләштерү өчен бик әйбәт форсат чыгар. Өс-башыгызны яңарту теләге генә түгел, моның өчен шәп мөмкинлекләр дә пәйда булыр.

КЫСЛА (22.06 – 22.07)
Дус-ишләрегез белән аралашканда үзегез өчен файдалы бер нәтиҗә ясап куанырсыз. Җылырак киенеп йөрергә тырышыгыз: суык тидерүегез бар. Атна ахырында әйбәт кенә керем көтегез.

АРЫСЛАН (23.07 – 23.08)
Соңгы вакытларда сөеклегез белән бераз суына төшкән үзара мөнәсәбәтләрнең кинәт кенә кайнарланып китүе сөендерер. Моңарчы үзегезгә үпкә хисе саклап йөргән бер туганыгыз белән дә араларыгыз җылыныр. Атна уртасында бик күп эшләргә туры килер. Әмма бу кәефегездә бары тик уңай чагылыш табар.

КЫЗ (24.08 – 22.09)
Телисезме-теләмисезме, гадәти тормыш рәвешен бераз гына үзгәртергә туры килер. Хәер, үзгәрешләр үзләре үк ыргылып керер. Аларның ничек булып бетәсе әлегә билгесез, әмма барысы да яхшыга булыр кебек.

ҮЛЧӘҮ (23.09 – 23.10)
Күптәннән күңелегезгә тынгылык бирмичә килгән бер мәсьәләгә ачыклык кертелер. Шул ук вакытта «Имәндә икән чикләвек» дигән гыйбарәне искә төшерергә туры килер. Ял көннәрендә телефон аша алынган хәбәр күңел кылларыгызны тибрәтеп җибәрер.

ЧАЯН (24.10 – 22.11)
Эшегезгә аяк чалырга маташучы бер адәмне кеше көлкесенә калдырырсыз. Бу хәл сезгә теш кайрап йөрүче башкаларга да бик әйбәт сабак булыр. Гомумән, көчле кеше икәнлегегезне күрсәтү җае бер-бер артлы чыгып кына торыр.

УКЧЫ (23.11 – 21.12)
Җитәкчегез белән юктан гына бәхәскә керүегез һәм хәтта дошманлашып китүегез бар. Эшне моңа җиткерергә кирәкми: үкенеп бетә алмаячаксыз, дип кисәтә йолдызлар. Атна ахырында күчемсез милеккә кагылышлы бер проблеманың очы күренә башлар.

КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12 – 20.01)
Җитәкчегез алдында яхшатланып, көлкегә калуыгыз бар. Шуңа күрә мондый кыланмыштан саграк булырга кирәк. Үзегезне яратучы кешеләр атна ахырында бик күңелле сюрприз ясар.

СУКОЯР (21.01 – 19.02)
Көтмәгәндә генә торак мәсьәләсен яхшыртуга өмет-ышанычлар уяныр. Дус-ишләр белән артыгын аралашмаска тырышу әйбәт: күңелегез кабул итмәгән бер хәбәрнең килеп ирешүе бар…

БАЛЫК (20.02 – 20.03)
Атна башында бик күп очрашу-күрешүләр көтелә. Шуңа да карамастан, барысына да өлгерәчәксез. Күп кенә эшләрегез моңарчы күрелмәгәнчә бик тә җиңел һәм тиз хәл ителәчәк. Ял көннәре яңа тәэсирләр белән сөендерәчәк.

БРИГАДА
СТРОИТЕЛЕЙ ВЫПОЛНИТ ВСЕ ВИДЫ РАБОТ

Телефон: 89600509692
Реклама

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ШЫГЫРДАТУ ГЫНА, ДИМӘ

Йоклаганда теш шыгырдату – күпләргә таныш күренеш. Еш кына аңа әллә ни игътибар да бирмибез. Сызламый, авыртмый, борчымый икән, борчылырга сәбәп юк дигәнрәк караш яши. Әмма белгечләр, йоклаганда теш шыгырдату җитди авыру билгесе дә булырга мөмкин, дип кисәтә. Бу очракта нинди авырулар турында сүз бара? Теш шыгырдатуның нинди сәбәпләре бар?

Теш табибы Эльвира АЛИМОВА шул сорауларга җавап бирде.

:: Ни өчен кеше йоклаганда теш шыгырдата?

– Йоклаганда кайберәүләрнең чәйнәү мускуллары кысыла. Шул сәбәпле кеше теш шыгырдата. Бу күренеш бруксизм дип атала. Ул еш кына стресс аркасында килеп чыга. Организм аңа шул рәвешле җавап кайтара. Теш казналары дөрес урнашмаган, тешләре җитәрлек санда булмаган, бозыла башлаган тешне саклау өчен киертелә торган металл тышча (коронка) дөрес сайланмаган очракта да кеше йоклаганда теш шыгырдатырга мөмкин. Ул өч тармаклы нерв ялкынсынуы, неврологик, борын авыруларының да беренче билгесе була ала.

:: Бу күренеш нәрсәсе белән куркыныч?

– Игътибарсыз калдырсаң, йоклаганда теш шыгырдату гадәте организмга зур зыян салырга мөмкин. Әйтик, йоклаганда даими рәвештә теш шыгырдаткан кешенең казналыклары авырта, эмале кыршылу аркасында, тешләре уала, коела башлый. Тора-бара кеше әйбер тешләгәндә дә авырту сизәргә мөмкин. Бруксизм баш авыртуга (мигрень) да сәбәп була ала. Теш шыгырдатканда организм тиешенчә ял итә алмый. Бу исә, үз чиратында, депрессия, нерв какшауга китерергә мөмкин. Бруксизм 7 яшькә кадәрге балалар арасында аеруча еш күзәтелә. Бу сөт тешләре чыгу, аларның төшеп, даими тешләргә алышынуына бәйле. Бала җиде яшьтән соң да теш шыгырдатса, белгеч белән киңәшләшергә кирәк.

:: Андый чакта кайсы белгечкә мөрәҗәгать итәргә?

– Бруксизмнан интеккән кеше иң беренче чиратта стоматолог-ортопед яки ортодонтка мөрәҗәгать итәргә тиеш. Ул теш казналыкларын, протез, коронка, пломбаларның ни рәвешле урнашуын тикшерәчәк. Кирәк икән, аларны төзәтеп тә җибәрәчәк. Бруксизмны дәвалау өчен, кешегә махсус пластик каплар киясе булачак. Аларны теш табибы белән бергә сайларга кирәк. Бу пластик каплар индивидуаль рәвештә, полимер материаллардан эшләнә. Аларны йоклар алдыннан кияләр. Ул аскы һәм өске тешләрне бер-берсенә тиюдән саклый. Нәтиҗәдә эмаль да сафтан чыкмый. Әгәр бруксизмның төп сәбәбе тешләргә бәйле булмаса, невролог яки психологка мөрәҗәгать итәргә кирәк.

:: Организмында бабасыр булса, бала йоклаганда теш шыгырдата, диләр...

– Мәктәпкәчә яшьтәге бала организмында еш кына паразит суалчаннар (гельминтлар) була. Шуңа күрә күпләр йоклаганда теш шыгырдатуның сәбәбен шуннан күрә. Имеш, гельминтлар аркасында организмда төкерек бүленеп чыгу көчәя. Бу исә, үз чиратында, казналык кысылуга, шуңа бәйле рәвештә теш шыгырдатуга китерә. Әмма күпсанлы тикшеренүләр моның бары тик очраклык булуын гына раслый. Баланың теш шыгырдатуы белән бабасыр арасында бернинди бәйләнеш тә юк.

pixabay.com

ЙОКЛАГАНДА ТЕШ ШЫГЫРДАТМАС ӨЧЕН БЕРНИЧӘ КИҢӘШ

➤Ярты елга бер тапкыр теш табибына, неврологка күренеп торыгыз.

➤Казналыкны көн дәвамында эшкә җигегез. Каты яшелчә, җиләк-җимеш кимерү аеруча файдалы.

➤Стресстан сакланыгыз. Ешрак елмаю, көлү, яхшы эшләр башкару, шоколад ашау моннан коткара.

➤Теш шыгырдатудан саклану өчен, кофе кебек энергетик эчемлекләр белән дә мавыкмау хәерле.



Киңәш-табыш

Тоз аякка хәл кертә

Арыган аякларга кул астындагы чаралар ярдәмендә дә хәл кертеп була. Моның өчен 1 стакан чистартылмаган көнбагыш маенда 1 чәй кашыгы аш тозын эретергә кирәк. Кич белән шуны аяк табаннарына һәм балтырларга яхшылап ышкып массажлагыз. Аннары аякка полиэтилен пакет өстеннән җылы оекбаш киеп, 30–40 минут тотыгыз да кайнар су белән юып, йокларга ятыгыз.

Бал ютәлдән коткара

Ютәлдән тиз арада котылу өчен, уылган алма белән суганны, балны бер үк күләмдә алып, бергә кушып болгатырга кирәк. Шуны көн дәвамында 3 тапкыр 1әр аш кашыгы кабасы.

Сары мәтрүшкә – буынга дәва

Буын авыртудан интеккәндә түбәндәге ысул ярдәмгә килер. 1 аш кашыгы киптерелгән сары мәтрүшкәгә 1 стакан кайнар су салып төнәтәбез. 15–20 минут тоткач, шуңа тукыма кисәген манып, авырткан урынга куеп торабыз. Өстенә пакет ябып, җылы итеп төреп куябыз. Бер сәгатьтән компрессны алабыз.

Чайкау шифа бирә

Стоматиттан интеккән кеше түбәндәге төнәтмәләр белән авыз чайкаса, шифасын сизми калмас:

◆бер аш кашыгы кипкән ромашка чәчәгенә бер стакан кайнар су агызыгыз. Суынгач, авызны шуның белән чайкатыгыз;

◆бер аш кашыгы кипкән меңъяфракка (тысячелистник) бер стакан кайнар су салыгыз да 20 минут термоста төнәтегез. Суынгач, сөзеп алып, шуның белән авызны чайкатыгыз.

Үзе дә, суы да файдалы

Эремчек суының шифасы әйтеп бетергесез. Анда сөт шикәре, минераль тозлар, тиз үзләштерелә торган аксым бар.

●Сөт шикәре эремчек суына эч йомшарта торган үзлек бирә. Шуңа күрә эч катканда, эремчек суы эчәргә киңәш ителә.

●Ул сидек кудырырга сәләтле, шешенүне бетерә.

●Моннан тыш эремчек суы ашказанындагы черүче флораны тышка куа, яшь, файдалы флора үстерергә булыша. Эремчек суын ач карынга – иртән эчәргә киңәш ителә. Көнгә бер стакан эчү җитә.

●Ябыгу өчен 1,5–2 литр эремчек суы кирәк. Аны көн дәвамында дүрт өлешкә бүлеп, шикәрсез чәй һәм су белән чиратлаштырып эчәргә киңәш ителә. Бу диетаны җиде көнгә бер тапкыр бер ай дәвамында кулланырга була. Ул организмны чистарта, ашказаны эшчәнлеген, матдәләр алмашын яхшырта. Эремчек суын бер атна дәвамында кичке аш урынына кулланып та артык авырлыктан котылырга була.

●Целлюлиттан да арынырга ярдәм итә. Моның өчен көненә бер стакан эремчек суы эчәргә кирәк.

●Моннан тыш, ул чәч һәм тырнакны да ныгыта.

Кояштан саклаучы күзлек сайлыйбыз

Кыйммәтрәге файдалырак дигән сүз дөрес леккә туры килми. Кояш күзлегенең ни дәрәҗәдә файдалы булуы аның бәясенә түгел, ультрашәмәхә нурлар (UVA һәм UVB) тәэсирен никадәр чикләвенә бәйле. Шуңа күрә кояштан саклаучы күзлек сатып алыр алдыннан ярлыгындагы санга игътибар итегез. Бу күрсәткеч зуррак булган саен, күзлекнең күзләр өчен файдасы да күбрәк булачак.

Кояш күзлегенең пыяласы калынрак булса яхшырак. Ник дигәндә, кара күзлек кигәч, безнең күз бәбәге зурая. Күзлекнең пыяласы юка булса, ультрашәмәхә нурлар аның аша җиңел генә үтеп кереп, күзләргә зыян салачак.

Пыяласында кыршылган эзләр булмаска тиеш. Алар аша караганда күзләргә икеләтә көчәнергә туры киләчәк. Бу исә күрүне начарлата.

Күзлекнең нинди төстә булуы мөһим түгел! Төсләр күрүгә бернинди йогынты ясамый.

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Гөлнара ЗИННӘТУЛЛИНА

МАТУРЫН ТҮГЕЛ, ЯШЕН САЙЛА

Апрель ахыры – май башы җимеш агачы һәм куаклары утырту вакыты. Бик матур, сәламәт дип сатып алган агачлар да кайчак җимеш бирми, йә тернәкләнеп китми. Моның сәбәбе нидә?

pixabay.com

Агач һәм куак сайлау серләрен һәвәскәр бакчачы Гөлфия ХӘНИПОВАдан сораштык.

:: Җиләк-җимеш агачын базар яки урамда сатып алганнан соң, җимеш бирми дип зарланучылар еш очрый. Бу нилектән булырга мөмкин?

– Җиләк-җимеш агачларына прививка ясалган булырга тиеш. Әгәр агачка прививка ясалган булса, аның урынында җөй кала. Сайлаган агачның кәүсәсендә әлеге билгене тапмасагыз, акчагызны суга салдыгыз дигән сүз. Нинди генә матур булса да, әлеге агач сезне җимешләре белән сөендермәячәк.

:: Агач яки куак үсентесе сатып алганда тагын нәрсәгә игътибар итәргә кирәк?

– Үзегезгә төгәл нинди агач яки куак кирәк икәнлеген аңлаганнан соң, аның тамырын карагыз. Алар шәлперәйгән һәм кипкән булырга тиеш түгел! Тамыр системасы зурлыгы агач яки куакның өске өлеше зурлыгына туры килүе дә мөһим. Агачы матур һәм нык күренсә дә, тамыры бик кечкенә икән, йә ул бик озак «авырып» тернәкләнә, яки бөтенләй дә китмәскә мөмкин.

:: Җимеш бирә торган агачның күзгә күренеп торган кәүсәсендә кырылган җирләре булса, алмавың хәерлеме?

– Әгәр агачның кәүсәләрендә бераз кырылган урыннары булса, аңа әллә ни игътибар итмәгез. Бу урынны «садовый вар» белән эшкәртеп куйсагыз, ул бик тиз төзәлер. Аны сатып алырга да, өй шартларында ясарга да мөмкин.

:: Сайлап алу мөмкинлеге булганда, агач үсентесенең зуррагын сайларгамы, әллә кечерәгенме?

– Кайчак сатучылар җылы яктан кайткан эре сорт дип, эре агач-куак үсентеләрен саталар. Алар бик матур һәм көчле булып күренсә дә, беренче туң төшүгә үк үләргә мөмкиннәр. Шунлыктан, тизрәк җимешен ала башлармын дип, зуррак үсенте алырга тырышмагыз. Ә яшь үсенте бик тиз тернәкләнә һәм үзеннән зуррак агачны да тиз генә куып җитеп, үзып китәргә, җимешне дә иртәрәк бирә башларга мөмкин. 2–3 еллык үсентеләрне сайласагыз, оттырмассыз.

:: Сатып алганнан соң үсентене шул көнне үк утырту мөмкинлеге булмаска да мөмкин бит.

– Әгәр ачык – туфраксыз тамыр системалы агач яки куак алган булсагыз, аны утыртканчы тамырын дымлы чүпрәккә төреп, пакетка салып торыгыз. Мондый хәлдә агачны салкын урында бер атнага кадәр, кайчак күбрәк тә сакларга мөмкин.

Тәмле булсын!

Эремчекле-какаолы пирог

Миләүшә СӘГЪДИЕВА рецепты

Камыр өчен кирәк:

280 г он, 180 г атланмай, 60 г какао порошогы, 80 г шикәр комы.

Эчлек өчен кирәк:

350 г эремчек, 80 г шикәр комы, 3 йомырка, 70 г каймак, 40 г крахмал.

Эчлек өчен кирәкле барлык ингредиентларны кушып, миксер белән яхшылап болгатырга.

Он, бүлмә температурасында бераз йомшартылган май, какао, шикәр комын кушып, яхшылап кул белән изәргә. Уалучан камыр барлыкка килә.

Камырның өчтән икесен форманың астына җәяргә, аның өстенә эчлек салырга, ә калган камырны эчлек өстенә салып чыгабыз. Пирогны 180 градуска кадәр җылытылган мичкә 40 минутка куябыз. Пешеп чыкканнан соң, аны бүлмә температурасына кадәр суытырга һәм пленка белән каплап, 1–2 сәгатькә суыткычка куярга. Бик тәмле була!

Тест

Чәчең сәламәтме?

Түбәндәге тест белән чәчнең сәламәтме әллә юкмы икәнлеген тикшереп карарга була. Бер бөртек чәчегезне йолкып алып, чиста су салынган стаканга салыгыз. Чәч өстә йөзсә, димәк, ул сәламәт, ә батса, чәчегезне яхшылап тәрбияләргә кирәк дигән сүз.

Белеп тор!

ПӘРДӘ БЕЛӘН ҖӘЙМӘ САЙЛЫЙБЫЗ

1 Әгәр пәрдә белән дивар бер тонда икән, караватжәймәсен пәрдәгә туры китереп сайламагыз.

2 Карават җәймәсе бүлмәдә хәйран урынны алып тора. Аңа төп игътибарны юнәлтергә уйлаганда, аның тонына туры килә торган ваза, картина сайлап, бүлмәне тагын да ямьләндерергә мөмкин.

3 Пәрдәне дивардан бик нык аерылып торган җете төстәгене сайлыйсыз икән, бу очракта җәймәне аның белән бер тонда сайларга киңәш ителми. Ике җете бер бүлмәдә артыграк булыр. Бу очракта пәрдәгә туры килә торган зур булмаган тар келәм яки мендәр булу да җитә. Җәймә нейтраль төстә булса да ярый.

4 Әгәр пәрдәнең төсе «тыныч» һәм дивар төсе белән туры килми икән, карават җәймәсен пәрдә төсендә сайларга да була. Ә җете төсләр кертергә теләсәгез, бүлмәне картина, пуф, кәнәфи, мендәрләр белән бизәп җибәрергә була.

Сорау – җавап

КУРА ҖИЛӘГЕ БЕЛӘН КАРЛЫГАННЫ ТУКЛАНДЫРУ

Карлыган белән кураны тукландыра торган нинди дер яхшы бер препарат бар дип ишеткән идем. Ул нинди препарат һәм аны ничек кулланырга?

Гөлназ ГАФУРОВА. Мамадыш

Сорауга бакчачы Рәмзия ӘХМӘДУЛЛИНА җавап бирде:

– Карлыган, кура, крыжовник, чия, слива, алмагачны тукландыруның бер бик җайлы гына ысулы бар. Моның өчен «Монокалий фосфат» препаратын кулланабыз. 10 литр суга 2 аш кашыгы препарат алына. Яхшылап болгатабыз. Алдан су сибеп куйган куак төпләренә икешәр литр, агач төпләренә зурлыгына карап, яртышар, берәр чиләк салабыз. Ашланган җир генә аш бирә. Тукландыргач, агач-куаклар ныгый, авыруларга, корткычларга каршы торучанлыгы да арта.

Үзем сынадым

Челтәрне тоз агарта

Узган ел челтәрләрне әлеге ысул белән агарткан идем, миңа нәтиҗәсе бик ошады. Җылы суда порошок белән бер уч тозны эреттем. Әлеге суга челтәрне салып, 3–4 сәгатькә салып куйдым. Әгәр челтәр бик нык саргайган булса, кич салып калдырырга да мөмкин. Аннары челтәрне юдым һәм кабат тозлы суда чайкап элеп куйдым. Үтүкләп элгәч, яңа челтәрдән бер дә ким булмады!

Сәрия ХӘБИБУЛЛИНА. Арча

ҮЗЕ СЕРЛЕ, ҮЗЕ ХӘЕРЛЕ

Рамазанның соңгы ун көнлеген дә ваклый башладык. Ел саен шушы чорда күңелне ымсындырып торган бер көн була. Ул да булса – Кадер киче. Мөселман кешесе өчен иң серле, иң кадерле кичләрнең берсе ул. Быел аны кайсы төннән эзләргә? Кадер кичен ничек уздырырга кирәк?

Лаеш районындагы «Ихлас» мәчете имам-хатыйбы Мөдәррис хәзрәт ГЫЙМРАНОВ шул сорауларыбызга җавап бирде.

:: Мөдәррис хәзрәт, иң элек Кадер киченең асылы турында сөйләшик әле.

– Коръәни Кәримдә Аллаһы Тәгалә рамазан ае турында әйткән вакытта берничә асылга таяна. Ул: «Рамазан аенда Коръән индерелде», – ди. Ягъни рамазан аеның бер бөеклеге – шушы айда Коръән индерелә башлау һәм индерүне тәмам кылуда. Хәдисләрдән белүебезчә, Кадер киче рамазан аеның соңгы ун көнендә яшерелгән. Бу көнне Аллаһы Тәгалә ләүхүлмәхфүздән Коръәнне иң беренче тапкыр дөнья күгенә төшерә. Аннан соң инде пәйгамбәребез Мөхәммәт Мостафа галәйhиссәлам аны 23 ел дәвамында җир йөзенә индерә. Шуңа күрә мөселман кеше өчен ялган белән хакыйкатьне аеручы, караңгыдан яктылыкка чыгаручы, кешеләрне туры юлга өндәүче бәхет, туры юл чыганагы, яшәү мәгънәсен аңлатучы, җәннәт белән сөендерүче, җәһәннәм белән куркытучы, Аллаһы Тәгалә турында сөйләүче, дөньяның барлыгы, кешеләрнең асыл мәгънәсе турында сөйләүче Коръән индерелү белән аеруча әһәмиятле ул.

Шушы кичтә һәрбер адәм баласының, илләрнең, шәһәрләрнең язмышлары да языла. Аллаһы Тәгалә бер сүрәдә: «Бу төндә Аллаһы Тәгаләнең хикмәтле, гыйлемле әмерләре таратыла», – ди. Хөсәен ибн Фадл дигән галимнән: «Аллаһы Тәгалә дөньяны яратканчы гамәлләрне тәкъдир кылмадымыни?» – дип сораганнар. Ул: «Әйе, тәкъдир кылды», – дип җавап биргән. «Алайса, бу төннең мәгънәсе нәрсәдә соң?» – дигәннәр. «Мәгънәсе – менә шушы тәкъдир кылынган гамәлләрне вакытына китерү һәм инде тәкъдир кылынган шушы гамәлләрне тормышка ашыруда», – дип җавап биргән ул.

:: Кадер кичен нинди билгеләрдән танып белергә була?

– Бер сәхабәдән: «Кадер кичен кайдан белдең?» – дип сораганнар. Ул: «Мин пәйгамбәребездән ишеттем: Кадер төне үткәч, икенче көнне кояш, түп-түгәрәк булып, нурларсыз чыгар», – дигән. Икенче бер хәдистә: «Ул төн ачык, тыныч булыр, анда бәрәкәт булыр. Ул ни җылы, ни салкын булмас, икенче көнне кояш нурлар чәчмичә чыгар», – диелгән.

:: Кадер кичен ничек уздырырга кирәк?

– «Кадер» сүрәсендә Аллаһы Тәгалә: «Ул төн мең айдан хәерлерәк», – ди. Ягъни 83 елдан да хәерлерәк ул бер төн. Мөхәммәд өмметенең бер үзенчәлеге бар. Ул да булса, без – ахыргы, иң кыска гомерле өммәт. Әмма безнең шушы гомеребезнең кыскалыгында да хикмәт ята. Пәйгамбәребез Мөхәммәт Мостафа галәйhиссәлам: «Кем дә кем, шушы кичәне Аллаһы Тәгаләнең рәхим-шәфкатенә, аның гөнаһларны кичерүенә өметләнеп, гыйбадәттә үткәрсә, аның үткән барлык гөнаһы да гафу ителер», – ди. Шуңа күрә шушы кичне гыйбадәттә уздырырга кирәк. Рәсүлебез рамазан аеның соңгы ун көнен мәчеттә үткәргән. Ул төннәрен гыйбадәттә булган, гаиләсен дә уяткан. Шуңа күрә бу кичне гыйбадәттә, зекердә, тәсбихтә, догада, Коръән, Тәһәҗҗуд намазын укып үткәрсәк, Аллаһы Тәгалә барлык гөнаһларыбызны да кичерәчәк.

:: Ни өчен Кадер киче яшерелгән? Быел аны нинди көннәрдә эзләргә кирәк?

– Аллаһы Тәгалә үзенең иң бөек исемнәренең берсен яшергән. Җомга көнендә исә дога кабул була торган сәгатьләрнең берсен яшергән. Адәм балалары шушы бер көнгә, бер сәгатькә генә басым ясамасыннар, гыйбадәтләрен күп кылсыннар, әҗерләре, иманнары, тәкъвалыклары артсын дип, Аллаһы Тәгалә шушы төнне дә яшергән. Аны нинди көннәрдә эзләргә дигәндә, хәдисләргә таянабыз. Кадер кичен рамазан аеның соңгы ун көнендә, так көннәрдән – 21, 23, 25, 27, 29 кичәләреннән эзләргә кирәк. Кадер киченең кайсы көнне икәнен бер кеше дә төгәл генә әйтә алмый. Кем дә кем шушы рамазан аеның соңгы ун көнендәге так кичәләрне гыйбадәттә үткәрсә, иншаллаһ, аны барыбер Кадер кичәнә туры китерәчәк.

dumrt.ru

:: Кадер кичендә теләгән теләкләр икеләтә кабул була, диюләре дөресме?

– Кадер кичендә бер еллык тәкъдир языла. Бу бары тик шушы кичтә генә эшләнә. Шуңа күрә аны ваемсызлыкта үткәрергә ярамый. Адәм балалары бу кичәнең бөеклеген, аның фазыйләтләрен белсәләр иде, күзләр йомылмасын, куллар догадан төшмәсен иде. Кадер киче мең елдан хәерлерәк булгач, бу төндә укылган намаз – мең ел укыган намаз, ул төндә бирелгән сәдака мең ел бирелгән сәдака кебек була. Теләкләр белән дә шул ук хәл.

КАДЕР КИЧЕНДӘ УКЫЛА ТОРГАН ДОГА

Рәсүлуллаh галәйhиссәлам Гайшә анабызга бу кичәдә уку өчен ошбу доганы өйрәткән: «Әллааhүммә иннәкә әфүввүн түхибүл әфвә фәфу әнни».

Мәгънәсе: «Аллаһым! Син – гафу итүчесең, гафу итүне сөярсең, мине гафу ит!»

:: Кадер кичендә нинди эшләрдән тыелып тору хәерле?

– Кадер кичендә үзен гыйбадәткә, зекергә багышлаган кешенең хәерсез гамәлләргә вакыты калмый. Аллаһы Тәгалә безгә бу айда, Кадер кичендә генә түгел, гомумән, һәрчак үзенең рәхмәтен, шәфкатен күрсәтә, безне яшәргә, гыйбадәт кылырга өйрәтә. Адәм баласы бер ай, бер кичә белән генә тукталмасын. Шуңа күрә рамазан ае – шушы тормышны ничек башлап җибәрергә кирәклеген төшендергән генераль репетиция ул. Кадер киче дә – гөнаһлардан арыну, Аллаhка якынаю өчен менә дигән форсат. Моң-зары булган кеше шушы кичне гыйбадәттә үткәрсен. Гөнаһларының күплегеннән кәефе кырылса, шушы кичәдә тәүбәләрен кылсын.

Ураза көндәлеге

СЕЗ СОРАГАН ИДЕГЕЗ...

Укучыларыбызның сорауларына «Казан нуры» мәчете имам-хатыйбы Алмаз хәзрәт Мөхлисов җавап бирде.

?Рамазан аен бик көтеп алган идем. Менә бер атнасын салкын тидереп, авырып уздырдым. Әле хәл кереп бетмәгән килеш уразага керсәм ярыймы?

– Ураза тоткан кеше сау-сәламәт булырга тиеш. Иң төп шартларның берсе бу. Кеше авырый икән, ураза тотмаса була. Ләкин авыру сәбәпле, ничә көн уразасын калдырган булса, рамазан ае беткәч, тотмаган көннәрен тотып бетерергә туры киләчәк. Әгәр кешенең хәле бераз яхшырган икән, бу очракта ураза тотарга кирәк.

?11 яшьлек улымның уразага керәсе килгән иде. Дәресләре дә күп, көн саен футболга йөргәч, әле ныгымаган организмга авырга килер дип уйладым. Мин шулай итеп хата кылдыммы?

– Балигъ булган кешегә ураза тоту фарыз. Бу очракта ата-анага бик игътибарлы булырга кирәк. Әгәр бала ураза тотарга тели икән, аны тыярга кирәкми. Балаларны кызыктыру йөзеннән үзебез дә ураза тотсак иде. 11 яшьлек бала берничә көн генә булса да ураза тотып караса, хәерле булыр. Ник дигәндә, ул моңа акрынлап ияләшәчәк. Аллаһы Тәгалә аңа үзенең ярдәмен бирә. Шуңа күрә бала ураза тотарга тели икән, аны тыймыйк. Юкса, балигъ булгач, ул уразаны бөтенләй тотмаска да мөмкин. Әле көннәр бик озын да, эссе дә түгел. Балаларны куркытмыйча, кирәсенчә, кызыктырып, ураза тоткан өчен бүләк биреп, аларны шатландырырга да онытмагыз. Кечкенәдән ураза тотарга ияләшсә, киләчәктә баланың үзенә дә җиңелрәк була.

?Ирем дә, үзем дә эшсез калдык. Ел саен корбан чалганлыктан, быел да корбан чаласыбыз килә. Финанс ягы авыр вакытта корбан чалу дөрес буламы?

– Корбан чалу кемнең хәленнән килә, кем матди яктан тәэмин ителгән – шуңа вәҗиб. Ул көмеш бәясенә карый. Бүген аның нисабы 39 мең сум тәшкил итә. Әгәр гаиләнең 39 мең сум акчасы бар икән, ул корбан чалырга тиеш була. Аның кадәр акча булмаса, бу гамәл мәҗбүри түгел. Бурычка алып, бик авыр хәлгә калып, корбан чалырга кирәкми. Мөмкинлеге булмаган кеше корбан чалмаса, гөнаһы булмый.

Бәхет үзеңнән башлана

Бер зирәк карт, язгы табигатька сокла-на-соклана, урам буйлап бара икән. Шунда, җилкәсенә зур йөк асып, көч-хәл белән атлап барган бер ир-атка игътибар иткән ул.

– Нишләп бу кадәр азапланасың? – дип сораган ул аннан.

– Балаларым, оныкларым бәхетле булсын өчен тырышам. Карт бабам бабаем бәхетле булсын дип тырышкан, бабай – әти, әти минем өчен дип тырышып, тир түгеп яшәгән. Мин үз балаларым бәхетле булсын өчен тырышам, – дип җавап кайтарган ир.

– Ә аларның берәрсе үзе бәхетле булганмы соң? – дип янә сорау биргән карт.

– Әлегә юк, ләкин оныкларым, балаларым бәхетле булыр дип ышанам, – дигән ир-ат.

– Акыллы наданны укырга өйрәтә, сукыр тычкан лачынны тәрбияли алмаган кебек, балаларың бәхетле булсын өчен, иң элек үзең бәхетле булырга кирәк! Синең аларга ясаган иң зур бүләгең шул булыр, – дигән зирәк карт.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

Лилия ГЫЙМАЗОВА

ГӨЛНАЗ БАТТАЛОВА:

«АЛЕКСКА ТАТАР ҖЫРЛАРЫ БИК ОШЫЙ»

Бүгенге «Ни хәл?» сәхифәсенең кунагы – Америка килене, танылган җырчы Гөлназ БАТТАЛОВА. Океан арты иленә күченү, кияүгә чыгу, тел барьеры, татар җырлары – без әнә шулар турында сөйләштек.

:: Ни хәл?
– Бар да яхшы. Әле менә Америкага, Лос-Анджелес шәһәренә күчендем. Болай тиз булыр дип үзем дә уйламаган идем. Дөньядагы вазгыять күчену процессына үз үзгәрешләрен кертте, билгеле.

:: Сөйгәнегез Алекс белән ничек таныштыгыз?
– Исемнәр татар халкында гомер-гомергә игътибар белән сайланган, электән үк мәгънәсенә җитди игътибар бирелгән. Исем кеше язмышына нык тәэсир итә. Нинди исем кушыла, бала да шундый була, дип фараз иткәннәр. Шуңа да бу мәсьәләгә җитди карaганнар. Хәзерге чорда да саклана бу. Әмма исемнәр кыскарды. Элек исемнәр берничә тирән мәгънәгә ия булган. Әйтик, Габделҗаббар, Мөхәммәтвәли. Әлбәттә, мондый озын, күпмәгънәле исемнәр кушуның сәбәбе – халыкның дини мохиттә яшәвендә. Сәяси вазгыятькә бәйле рәвештә, совет чорында халык диннән ераклашты. Ниндидер сәеррәк исемнәр кушыла башлады. Европага бәйле исемнәр керә. Төрки-татар исемнәре алай да күп кушылды. Хәзер дә бераз начаррак тенденция күзәтелә. Халыкның диннән ераграк булуы исемнәрнең мәгънәсенә игътибар итмәүгә китерә. Кайсыларын үзләре дә аңламый. Мәгънәле исемле кешеләр мәгънәле гомер кичерә, тәҗрибә шуны күрсәтә.

Рөстәм хәзрәт ХӘЙРУЛЛИН, «Гаилә» мәчете имам-хатыйбы:

– Рәсүлебез (с.г.в.): «Исем алмаштырып кына язмышлары үзгәрә дип уйламасалар, тизрәк тау күчәр иде», – дигән. Пәйгамбәребез хәдис-шәрифләрендә дә: «Йөрәк турысындагы бер кисәк чиста булса, бөтен тән чиста булыр», – ди. Ягъни йөрәкне начарлыктан арындырырга кирәк. Хәерсез исемнәр кушудан тыелырга, мәсәлән. Ата-ана кушкан исем төпле, яхшы мәгънәле икән, аны үзгәртергә кирәк түгел. Мәгънәсез исемне сайлыйлар икән, аңлатырга, башка матур исемнәр тәкъдим итеп карарга була.

ЧЕРНОБЫЛЬНЕҢ КАРА КӨННӘРЕ

МОННАН 36 ЕЛ ЭЛЕК, 26 АПРЕЛЬДӘ ЧЕРНОБЫЛЬ АТОМ СТАНЦИЯСЕНДӘ КӨЧЛЕ ШАРТЛАУ БУЛДЫ

Бу вакыйга тарих битләрендә мәңге җуелмас кара нокта булып калды, чөнки Чернобыльдәге һәлакәт техноген фаҗигаләр арасында күләме, зыяны буенча дөньяда иң зур афәт китергәне булып санала.



Бүген ниләр бар?

Чернобыльдә фаҗигагә тарыган бу атом электр станциясе Украинада махсус операция башлануга, инде 24 февральдән үк, күзәтү астына алынды. Россия хәрбиләренең беренче көнне үк бу тарафка юл алулары аңлашыла, әлбәттә. Атом электр станциясе – куркыныч объект, монда бернинди атыш булырга да, корал кулланылырга да тиеш түгел. Өстәвенә Украина президенты Владимир Зеленский Украинада, станциядәге атом-төш калдыкларыннан файдаланып, «пычрак бомба» җитештерергә мөмкинлек булуы турында игълан итте. Әлбәттә инде, мондый шартларда АЭСны саклау – һичшиксез, иң мөһим, беренче чираттагы бурыч. Матбугатта бирелгән хәбәрләрдән күренгәнчә, моның шулай икәнен хәтта станцияне саклаучы Украина гаскәрләре дә аңлый. Коралларын тапшырып, алар энергоблокларны, саркофагларны, атом-төш ягулыгы калдыкларын россиялеләр белән бергәләп саклыйлар. Андагы хезмәткәрләр дә эшләрен гадәттәгечә дәвам итәләр.

Махсус операция башлангач та, станциядә «Россия» телеканалының «Яңалыклар» программасы журналисты Михаил Федотов булып кайтты. Ул андагы вазгыятьне баян итте. «Станциядәге энергоблоклар 2000 елдан бирле эшләми. Алар туктатылган, әмма суынып бетәр өчен, технология буенча берничә дистә ел кирәк икән әле. Атом-төш ягулыгы калдыклары контейнерларда, коры принцип буенча саклана.

Бер бинада камералар куелган, монитор алдында Россия белән Украина милли гвардиясе хәрбиләре бергәләп күзәтүләр үткәрәләр. Украина хәрбие әйтүенчә, монда куркынычсызлык системасы кат-кат кайгыртылган, калдыклар тутырылган контейнерлар җимерүгә бирешми, радиоактив калдыкларны чыгару һич кенә дә мөмкин эш түгел икән. Хезмәткәрләр белән дә үзара хезмәттәшлек җайга салынган. Нурланыш куркынычсызлыгы цехы белгечләре хәрбиләр белән бергә дозиметриягә кагылышлы бөтен мәгълүматларны контрольдә тоталар».

Куркыныч тәҗрибә

Ике як арасындагы мондый баш китәрлек бердәмлеккә, бәлки, гаҗәпләнәсе дә түгелдер. Атом-төш сугышында җиңүчеләр була алмый, дигән гыйбарәне барыбыз да яхшы беләбез бит. 36 ел элек булган фаҗигане күреп кайтканнар бигрәк тә. Тукай районы Күзкәй авылында яшәүче Нәкыйп Вәлиев тә – шундыйларның берсе. Газетаның актив хәбәрчесе, китапханәче Тәнзилә ханым Шәйхнурова ел саен, Җир шарына нинди куркыныч янаганын белеп торсыннар дип, аның янына балаларны җыеп алып бара. Бу юлы Нәкыйп Вәлиев аларга менә ниләр сөйләгән:

– 1987 елның 26 ноябрендә хәрби комиссариаттан чакыру килде. Чернобыльгә җибәрәсен әйттеләр. Башта Оренбург өлкәсенең Тоцк шәһәрендәге хәрби лагерьда әзерлек курслары үттек. Анда химик-разведчик белгечлеге алдым. Батальон составында Чернобыльгә килеп төштем. Атом электр станциясенә 30 чакрым кала туктадык. Палаткаларга урнаштырдылар. Сулыкларда юынмаска, су эчмәскә дип катгый кисәттеләр. Шешәләрдә минераль су алып килделәр, шуны эчтек, юындык, теш чистарттык. Беренче көнне үк коры ютәл башланды. Үпкәгә һава җитмәде. Авыз кипте. Аннан чатнап баш авырта башлады. Тора-бара күндек. Иртәнге алтыда торып, ашап-эчкәч, станциягә эшкә китәбез. Бер бүлмәдә чишенеп, махсус костюм, битлек киябез. Үлчәү приборын тотып, станциягә кереп китәбез. Кергәндә-чыкканда марганцовкалы суда аяк киемнәрен чайкыйбыз. Шунда ук экраннан бөтен гәүдә күренә. Кайсы урында нурланыш бар, шунда кызыл булып яна. Алданрак килгәннәр бер сукмактан гына йөрергә кирәклеген аңлаттылар. Станциядәге эш вакыты тәүлегенә бер сәгатьтән артмаска тиеш иде. Рәсми рәвештә 25 рентген нурланыш алырга ярады. Шул нормага җитсә, куркыныч зонага башка кертмәделәр, кайтарып җибәрделәр...

Үз теләге белән

Татарстанлыларны Чернобыльдә фаҗига булуга җибәрә башлыйлар. Бу хәл 1990 нчы елларга кадәр дәвам итә. Шул вакыт эчендә анда 3907 кеше барып кайта. Шуларның 2700е – армиягә яңа чакырылучылар. Республиканың зур предприятиеләре ярдәмгә үз белгечләрен җибәрә. «Татарстан-86» төзелеш отрядыннан 91 студент та була. Якташларыбыз нигездә реакторны каплау, авария булган урыннарны чистарту белән шөгыльләнә. Чернобыльгә үз теләге белән килүчеләр дә күп була, чөнки хезмәт хакы мулдан түләнә. Акча эшләп кайту теләге барысыннан да өстенрәк була, күрәсең.

Тарих битләреннән күренгәнчә, белгечләрдән кала, беренче мәлдә җирле халык та, авария нәтиҗәләрен юк итәргә килүчеләр дә нурланышның ни дәрәҗәдә зыян китерүен аңлап бетермиләр. Күлдә коенучылар, бакчадагы җиләк-җимеш белән сыйланучылар, җәе туры килгәндә дип, кояш астында ләззәтләнүчеләр дә табыла. Кайберәүләр, файдасы күп икән дип, үз-үзен ышандырып, эчүчелеккә сабыша. Исән калган чернобыльчеләр әйтүенчә, бүген кемдер яши икән, димәк, ул саклану чарасын күргән. Әмма барысы да «үзенә тиешлесе»н алып кайткан.

ЧЕРНОБЫЛЬЧЕЛӘРГӘ ФЕДЕРАЛЬ ТАШЛАМАЛАР:

✓торак җирне яхшыртуга мохтаҗларны бер тапкыр фатир белән тәэмин итү;

✓торак һәм коммуналь хезмәтләргә түләү өчен 50 процент күләмендә ташлама;

✓гомуми милеккә ремонт ясау өчен кертелгән взноска 50 процент күләмендә ташлама.

Авария серләре яшерен булу сәбәпле, чернобыльче статусын бары тик биш елдан соң гына кабул итәләр. Беренче-икенче елларда аварияне юк итүдә катнашучыларга, авыруларын фаҗигагә бәйләп, нәрсәдер исбатлау бик авыр була инде. Татарстан буенча «Чернобыль оешмасы» берлеге Александр Барсков әйтүенчә, 1997 елга кадәр әле күп авырулар белән инвалидлык рәсмиләштерергә мөмкин булган. Әмма бу исемлек ни өчендер елдан-ел кыскарган. Калганнары нигездә онкологиягә бәйле булган. Ташламалар күп булса да, аларның күбесе бирелмәгән.

Кемгә – сагыш, кемгә – табыш

Ышанырлык та түгел: шундый куркыныч урын кебек тоелса да, авария булган җирдән туристлар өзелеп тормаган. Бу, белгечләр әйтүенчә, үлем казанына баш тыгу кебек булган инде. Туристлар Припять шәһәренә килгәннәр, урамнарда йөргәннәр. Мондый сәяхәтләр аларны оештыручыларга шактый гына табыш та китергәндер дип уйларга урын кала. Мәгълүмат чараларыннан күренгәнчә, соңгы вакытларда, сәламәтлеккә бик куркыныч булуга карамастан, Владимир Зеленскийның атом электр станциясенең үзәгенә сәяхәтләр оештыру теләге бик көчле булган. Тик, ни сәбәпледер, барып кына чыкмаган. Бәлки, өлгерми калгандыр.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Сан

Чернобыль атом электр станциясендәге авария нәтиҗәсендә Белоруссиядә нурланыш белән зарарланган территориянең мәйданы – 46,5 мең кв. км. Бу – барлык территориянең 23 проценты. Украинада 12 өлкәдә 50 мең кв. км җир, Россиядәге 19 төбәктә 60 мең кв. километрга якын җир зыян күргән. Гомумән алганда, бу һәлакәттән Европаның 10 илендә 145 кв. км җир зарарланган дип исәпләнә.

Чернобыльдәге авария нәтиҗәләрен юк итүгә 600 меңнән артык кеше җәлеп ителгән.

13 БАЛА ӘНИСЕ АЛЬБИНА ХӘЙДӘРШИНА:

«УЛ-КЫЗЛАРЫМНЫ ҮЗЕБЕЗ ӨЧЕН ТАПТЫМ»

Сөбханалла! Башкортстанның Балтач районында яшәүче 45 яшьлек ханым шушы көннәрдә 13 нче баласын тапкан. Сабый өч килодан артык булып туган, әнисе дә үзен бик яхшы хис итә икән. Малайга Байрас дип исем кушканнар. Хәзер гаиләдә җиде малай, алты кыз үсә. Без герой ананы эзләп таптык.

Әмма тиз генә элемтәгә кереп булмады. Альбинаның бер генә минут буш вакыты да юк икән. Безнең белән аралашканда, пирог пешергән чагы иде.

– Аллаһы Тәгалә биргән балаларның барысын да таптым. Аларның һәркайсы үз ризыгы белән туа бит. Мин балаларымның тормышта үз урынын табасына ышанам, – дип сүз башлады ул. – Олы баларны оядан чыгарып җибәрдек инде. Кызым Элита кияүдә. Аның ике баласы бар. Күптән әби инде мин. Кызым гаиләсе белән Бирск шәһәрендә яши. Улым Артур, авыл хуҗалыгы университетын тәмамлап, бер төзелеш оешмасында хезмәт куя. Өченче балабыз Альмир Уфа нефть университетын тәмамлады. Армиядә ул. Айгиз белән Айназ – студентлар әле.

Шулай итеп, өйдә тагын сигез бала тәрбияләнә. Альбинаның ире Уфага йөреп эшли. Өйгә елларда гына кайта икән. Әле мал-туар да тоталар. Бөтен эш – Альбина җилкәсендә. Әмма ул бер дә зарланмый. Вакытны ничек җиткерәсе икән, дип кенә баш вата.

– Мин 18 яшемдә кияүгә чыктым. Ул вакытта ирем Винергә 23 яшь иде. Без Балтач районының Югары Карыш авылында яши башладык. Анда зур итеп йорт салдык. Әмма балалар туа башлагач, авылда аларга мөмкинлекләр аз икәнен аңладык. Җыендык та район үзәгенә күчендек. Монда тагын йорт салырга туры килде, – дип сөйли Альбина. – Мин үзем – гаиләдә бер генә бала. Бертуганнары булганнардан көнләшеп яшәдем, минем дә энеләрем, сеңелләрем булып, зур гаиләдә яшисе иде, дип теләдем. Шөкер, Аллаһы Тәгалә үземә балаларны өеп бирде. Аларның һәркайсын яратам. Сәламәтлегем булганда, алып кайтам инде. Кечкенә улым карында чакта бер дә борчымады. 45 яшемдә булсам да, җиңел күтәрдем. Мин аның туганын да сизми калдым.

Бар эшне бергәләп эшли алар. Уллары да ярдәм итәргә генә тора. Альбина үзе дә – иртәдән кичкә кадәр аякта. Иң элек малларын карый икән. Алар күп. Ике сыер, ике бозау, ике үгез асрыйлар. Сарыклары да бар. Аннары инде Альбина балаларның кайсын мәктәпкә, кайсын бакчага озата. Дәресләре беткәч, тагын килеп ала.

– Балалар өйгә соң кайта. Көнем аларны бер түгәрәктән икенчесенә йөртеп уза. Берсен алып кайтып куям, икенчесенә китәм. Машина да йөртергә өйрәндем. Кая барасың, башкача булмый. Әмма зарланмыйм. Балалар күп булу – зур бәхет бит ул. Иң мөһиме: исән сау булсыннар. Миңа шул җитә, – ди ул. – Мәктәптәгеләрне йөртүен йөртәм, тик менә еш кына бакчадагыларын алырга онытам. Инде язып та куям. Менә шулай ул, балаларны җыеп бетерү дә җиңел түгел.

Атна ахырларына өйләрендә 20дән артык кеше җыела икән. Әле улларының дуслары да кунакка килә, ди. Альбина үзе, ул чит балаларның килгәнен дә, киткәнен дә белмим, дип шаярта. Күңеле киң аның. Үзенекеләргә генә түгел, чит балаларга да якты чырай күрсәтә.

– Гаилә зур булгач, ризык та мулдан әзерләнә. Ит белән бәрәңгедән өзелгән юк безнең. Зарланмыйча яшәр өчен, күп итеп мал асрыйбыз. Эшлибез дә, ашыйбыз да. Өйдә кеше күп чагында бер пешергәндә бер чиләк бәрәңге китә. Мантыйны ике кәстрүл пешерәбез, ул әзерләнгәч, тагын ике кәстрүл куябыз. Ипине үзебез пешерәбез, печенье, тәмле әйберләр безнең өчен кыйммәткә төшә. Шуңа да пироглар пешерәм. Анысын санап тормыйм, унлап таба пешә инде, – ди Альбина.

Хәйдәршиннарның мәктәптә укучы кызлары да кул астына керә башлаган. Энеләренә күз-колак булып торалар. Әниләре өчен монысы да – зур ярдәм. Күп булгач, алар бик тату, ди Альбина.

– Балаларым ярдәмчел. Бер-берсен саклап, яклап торалар. Ирем белән һәр балабызны аякка бастырыр өчен тырышабыз. Зурларын башта мәктәптә, аннан вузларда укыттык. Хәзер чират – кечкенәләрдә. Тәүфыйклары булсын иде инде, – ди 13 бала анасы.

Ул «Ана даны» медаленә дә лаек булган. 2014 елда Россия Президенты Владимир Путин Хәйдәршиннарга «Ата-ана даны» орденын да тапшырган.

– Без балаларны дәүләткә ышанып тапмадык. Дөрес, пособие түлиләр. Әмма ул җитми. Хәер, эш анда да түгел. Балалар үзебезгә кирәк. Картлык көнебездә таяныч, бер-берсенә иптәш алар. Әле мин үземне карт дип санамыйм. Күңелем, йөрәгем яшь әле. Бар шатлыгым – балаларда. Шуларны үстереп, игелек күрергә насыйп булсын иде, – ди Альбина.

Кызы Элита исә әнисе кебек күп бала табарга җыенмый.

– Әти белән әни инде хәзердән туганнарымның исемнәрен бутап сөйләшәләр. Шуңа күрә миңа өчәү дә җитә, – ди ул.

ӘТИ ҖЫЛЫСЫ

Апас районының Урта Балтай авылында күпләргә үрнәк әти яши. 38 яшендә тол калып, ике баласын берүзе үстерә. «Безнең әти кебек кеше башка юк ул», – ди Илфир Гәрәевнең кызы Илүзә.

– Әнием Ләйсәнсез калганны хәтерлим әле. Ул чакта миңа 10 яшь иде. Әни кинәт авырып китте. 3–4 көн генә авырды ул. Үлем турында еш әйтүе истә калган. Ул чакта бу сүзләргә артык игътибар да итмисең бит инде. Әнисез калырбыз, дип башыма да китермәдем, – дип искә ала Илүзә. – Ул көнне әти безне дәү әниләрдә калдырып, әнине Яшел Үзәнгә хастаханәгә алып китте. Шуннан исән кайтмады инде. Авыр хәбәрне безгә башта әйтми тордылар. Ике яшьлек сеңлем бу чакта берни аңламый иде. Әни әтинең туган көнендә күзләрен мәңгегә йомды.

Илүзә йөрәк авырулы булып туа. 8 ай чагында аңа катлаулы операция ясыйлар. Әнә шуңа да аңа артык борчылырга кушмыйлар. Сабый гына булса да, ул әнисез калу хәсрәтен күтәрә ала. Елаган чаклары да күп була. Ә менә сеңлесе Зилә, әнисез калгач, һәр төнне елап чыга. Әтисенә, әнине алып кайт инде, зинһар, дип ялвара. Илфир абый үзе ничек түзгәндер, белмим. Әмма балалары янында күз яшен күрсәтми ул. Тыштан шулкадәр нык, сабыр кешегә охшаса да, хатынын сагынып, әле дә сиздерми генә күз яшен коя икән. Илүзә шулай ди.

– Әле менә кичә генә иртәнге бишкә кадәр йокламыйча сөйләшеп яттык. Әнине искә төшерәбез. Хәер, аны онытканыбыз да юк инде безнең. Ничек итеп онытып була соң? Әни бит ул! Әтием сеңлемә беркайчан да, әниең үлде, димәде. Ул аны гел, озакламый әниең кайта, дип юатты. Әти үзе дә әнине сагына. Шулкадәр яратып та яшәп була икән, – дип гаҗәпләнә Илүзә.

Әти-әнисенең танышуын да кызык итеп сөйләп бирде кызлары. Илфир абый туган авылы Аюкәйдергәннән Урта Балтайга укытырга килә. Ләйсәннең Казанда соңгы курста белем алып йөргән чагы була. Алар тукталышта очраша. Әмма бер-берсенә сүз катмыйлар. Шул чакта Ләйсән дусларына: «Авылга бер чибәр егет килде, үземнеке була», – дип кыр кистереп әйтә. Күп тә үтми, инглиз телен укытырга кайта ул. Менә шунда яшьләр бер-берсен ошата. Тик бәхетләре генә озын гомерле булып чыкмый.

– Әни әтинең төшенә еш керә. Андый көнне ул елмаеп кына йөри. Без әтигә бик рәхмәтле. Бердән, безне ташламаган. Өйләнеп, безне чит кешедән кактырмаган. Икенчедән, әнинең рухын саклый. Мондый ирләр юк бит инде ул хәзер, – ди Илүзә.

Кызга – 22 яшь. Ул Урта Балтай участок хастаханәсендә шәфкать туташы булып эшли. Яшел Үзәндә укып кайткан.

– Мин эштән куркып үсмәдем. Балачагым булмады да диярлек. Әтием башта укытты, соңрак мәктәп директоры булды. Аннары район хакимиятендә эшләде. Хәзер инде җирлек башлыгы. Шуңа да өйдәге эшләрнең күбесе миңа эләкте. Элек мәктәптән кайтуга, өстемне дә салмыйча, маллар янына чыга идем. Аннары инде тизрәк сеңлемне алырга бакчага йөгерәм. Кичке якта ашарга әзерләргә кирәк, – ди ул. – Әмма әтием дә барысына вакыт таба иде. Сыерын да сауды, катыгын да оетты, тәмле коймаклар да пешерде. Безнең күңелне күрер өчен, токмач басып, аш та пешергәне бар. Хәзер инде аш бүлмәсендә күбрәк үзебез булырга тырышабыз. Аш-су серләренә әтидән һәм дәү әнием Рузиядән өйрәндем.

Илүзә моның өчен әнисе ягыннан туганнарына бик рәхмәтле икәнен яшерми. Алар әни җылысын бирә алмасалар да, кызларга бик ярдәм итеп торалар икән.

– Елга ике тапкыр Коръән ашы уздырабыз. Беренчесен – әнинең, икенчесен әтинең туган көнендә үткәрәбез. Ул көннәрдә күңелгә аеруча авыр. Их, әни исән булсамы! Ничек бәхетле яшәр идек без! Күп вакыт гел шулар турында уйланам. Әни җылысы нинчә яшьтә булса да кирәк бит ул, – ди Илүзә. – Без гомеребез буе әтигә бурычлыбыз, аның сабырлыгына сокланабыз. Алтын кеше ул. Беркайчан ачуланмый. Гел кешеләргә ярдәм итәргә ашыга. Күңеле изге аның. Безнеке кебек әтиләр күбрәк булсын иде.

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

МАРАТ ӘМИРХАНОВ:

«МИН АЛГАН ТӘРБИЯ ХӘЗЕРГЕ КӨНГӘ БӨТЕНЛӘЙ ТУРЫ КИЛМИ»

Зур эшләр башкарып та, күләгәдә кала. Язучы Марат ӘМИРХАНОВ турында әнә шулай дип әйтергә була. Юкса «Бибимәмдүдә абыстай» китабы өчен генә дә зур исемнәргә дәгъва итәргә хаклы ул. Тукайның анасы исемен тулысынча аклаган бу әсәр кайчан һәм нинди шартларда язылган? Әлеге әсәрдә моңарчы билгеле булмаган нинди фактлар ачылган? Тукай шәхесенә кагылышлы тагын нинди сәхифәләрне барларга кирәк? Без олпат язучы белән әнә шулар хакында сөйләштек.

dumrt.ru

:: Марат абый, сез – Тукайның анасы Бибимәмдүдә абыстайның исемен аклаган язучы. Туган елы да билгеле булмаган бу шәхескә алынуның сәбәпләре нидә?

– Без һәр елны Балтач районының Сасна Пүчинкәсе авылына Бибимәмдүдәнең каберен яд итәргә барабыз. Бу – күптән килгән гадәт инде. Барган саен, Бибимәмдүдә шәхесе әдәбиятта ни дәрәҗәдә яктыртыла, аның образы әсәрләрдә урын алганмы, дип уйлана идем. Ә бит Мәмдүдә образы шигърияттә бераз кулланылса да, прозада аны сурәтләгән чәчмә әсәр юк. Шуннан «Казан утлары» журналы редакциясенә бардым. «Егетләр, Бибимәмдүдә турында әсәр язу нияте бар, ничек карыйсыз?» – дип сорадым. Баш мөхәррир Илфак Ибраһимов та, проза бүлеге мөдире Камил Кәримов та бик хуплап каршы алдылар. «Бибимәмдүдә абыстай» повесте 2016 елның апрелендә басылып та чыкты.

Кем ул Бибимәмдүдә абыстай? Сер түгел, без аны гомер буе читкә кактык. Аңа карата аерым игътибарга лаек түгел дигән фикер тудырылды, исемен әйтмәскә тырыштык, күз йомдык. Әлеге сәясәт дәреслекләргә дә күчте. Тукай шулкадәр бәхетсез яшәгән, дөньясы шулкадәр җитешсез булган, хәтта әнисе дә үз итмәгән, ташлап, кияүгә чыгып киткән, дигән фикер безгә мәктәп эскәмиясеннән сеңдерелде. Минем шул сәясәтне бозасым килде. Бибимәмдүдәнең әдәби-мәдәни, милли дөньяда үз урынын кайтару, образын халыкка җиткерү теләге туды.

Беренче повестьны халык яратып кабул итте. Шуннан соң боз кузгалды. Мин өч ел гомеремне шагыйрьнең туган-тумачасын, яшәгән мохитен өйрәнүгә багышладым. Нәтиҗәдә бер-бер артлы «Зиннәтулла хәзрәт», «Сәҗидә», «Газизә», «Зәйтүнә» әсәрләре туды. Әсәрләр тәмам булгач та, аларны халыкка җиткерү теләге белән яна башладым. Чөнки 2019 елда Бибимәмдүдә абыстайның тууына 155 ел тула иде. Ни кызганыч, бу датаны исәпкә алып, ниндидер чаралар үткәрергә атлыгып торучылар гына юк иде. Кайларда гына чыгыш ясасам да, Тукайның әнисенең тууына 155 ел тула, дип искәртеп карадым, әмма колакка элүче булмады. Башка юлдан барып булмасмы дип, Татарстан Президенты каршындагы мәдәният фондына мөрәҗәгать иттем. Ул чакта үз көчем белән «Бибимәмдүдә абыстай» дигән китапны биш йөз данә чыгарган идем инде. Гозерем абыстай рухына мәчеттә Коръән чыгу мәҗлесе үткәрүдән гыйбарәт иде. Бу фикеремне бик җылы кабул иттеләр, нәтиҗәдә 2019 елның 22 феврале – Бөтендөнья туган тел көнендә Мәрҗани мәчетендә теләгем тормышка ашты. Аның финанс ягын шушы фонд үз өстенә алды, оештыру эшләренә татар филармониясе, Диния нәзарәте катнашты. Шулай итеп Бибимәмдүдә образы азмы-күпме дөньяга чыга башлады. Мин моңа бик шатланам һәм горурланам.

:: Бибимәмдүдә абыстай турында фактларны ничек таптыгыз, нинди чыганакларга таяндыгыз?

– Чыганаклар – истәлекләр. Алар бар, ләкин кемнең ничек язганын, кайсының чынбарлыкка туры килгәнен, ә кайсы гайбәткә тартым икәнне ачыклыйсы бар бит әле. Анысына чагыштыру юлы белән төшенәсең. Билгеле бер вакыйга өч истәлектә бер төрле язылса, аңа ышанырга була. Ә истәлекләрнең иң кадерлесе һәм миңа ярдәм иткәне – Зәйтүнәнең килене, Атилла Расихның хәләл җәфете Зәкия апа Рәсүлова язмалары булды. Зәкия апа – география укытучысы. Без аның белән «Сөембикә» журналында эшләгәндә танышкан идек. Ул шул чакта «Тукай эзләреннән» дигән кечкенә генә китап чыгарды. Зәкия апа, Тукай замандашларының исәннәре белән үзе күрешеп, аларның истәлекләрен язып алып, фактларны өйрәнеп яза. Шул рәвешле Тукайның 33 якын туганы белән аралаша. Аның китабы иң дөресе, игътибарга лаеклы, иң хакыйкатьлесе. Чөнки ул аны үзен алга куеп түгел, фәкать Тукайны ярату хисе белән яза.

Зәкия апа турында сүз чыккан икән, тагын бер фактка тукталыйк әле. Тукайның «Исемдә калганнар»ында үги әбисе Латыйфа карчык турында да сүз бар. Ул анда: «Ияреп килгән алты бала арасында мин бер чәүкә кебек идем», – дип яза. Бу җөмлә мине бик тынгысызлады. Чөнки Латыйфа 18 яшендә Зиннәтулла йортына аяк баса. Бәс, шулай икән, берничек тә килгәнче 6 бала тудыра алмый бит инде. Зәкия апа – Тукайның бу сүзләренә беренче булып каршы килгән һәм гаделлекне ачкан кеше. Уфа архивларында эзләнеп, ул балаларның шәҗәрәсен табып, аларның Зиннәтулла хәзрәт белән Латыйфа абыстайның үз балалары булуын язып чыкты. Аларның берсе дә ияреп килмәгән. Димәк, Тукайның һәр сүзе хакыйкатькә туры килә дигән сүз түгел әле.

Адәм баласының төрле чагы була, кызып киткән чагы, ачулы-үпкәле, кайтып төшкән мәле. Тукайның «Исемдә калганнар»ында да шулай ул. Шагыйрь үзе дә *«Бу урыннан игътибарән тәрҗемәи хәлемне үземнән хикәя итүне күңелем каклы тапканга, «булган»ны – «булды»га, «йөргәнмен»не «йөрдем»гә алмаштырам»*, – ди. Ягъни моннан калганнарын кеше сөйләве буенча яза. Кем ничек сөйли бит...

:: Анасы Өчилегә кияүгә чыгып киткәч, Тукайны үзенә алып калган Шәрифә карчык чынлыкта явыз булганмы соң?

– Шәрифә карчыкны без шулай ук гомер буе сүгеп, иң зур золымчы буларак кабул иттек. Мескен карчыкны Тукай әйткәнгә таянып сүккәнбез, ә чынбарлыкны ныклап тикшерүче булмаган. Тикшергәндә исә бөтенләй башка мәгълүматлар чыга. Шәрифә карчыкта Тукай бары тик ике айдан артыграк кына тора. Карчык аны бер кибән арыш бәрабәренә алып кала. Хәер, Тукай: «Ул карчык үлгән инде. Аллаһ аңа рәхмәт итсен», – дип тә яза бит. Ачу тотмыйм дигән сүз инде бу.

:: Гади укучы Мәмдүдәнең ике бала белән тол калган иргә кияүгә чыгуын да бик белмидер әле.

– Бибимәмдүдә бик чибәр була. Чыгышы, ерак бабалары, ыру-нәселе Чулман, Агыйдел буйлары төбәгенә бәйле булгангадыр, килеш-килбәте, төс-кыяфәте башкалардан аерылып тора. Истәлекләрдә аны «озынчарак йөзле, сызылып киткән кара кыйгач кашлы, матур кылыч борынлы, төскә-биткә чибәр, матур буй-сынлы, кирәк чакта шигырь белән җавап бирә торган оста телле, тегү-чигүгә маһир, мөлаем сылу» дип тасвирлыйлар. Алма кебек кыз. Мулла кызы. Аның кулын сораучылар да бихисап булгандыр. Ләкин, ни сәбәпледер, 21 яшькә кадәр ул кияүгә чыкмый. Ә бу – ул чакта шактый олы яшь. Бәлкем ул кулын сораган кешеләрне ошатмагандыр. Бәлкем үзенә тиң ирне көткәндер, анысын тәгаен фаразлый алмыйбыз. 21 яшен тутыргач, әтисе аны 43 яшьлек хәзрәткә кияүгә бирә. Мөхәммәтгарифның Камилә исемле хатыны гүр иясе булып, Мөхәммәтшәриф исемле угыл, Газизә исемле кызы белән тол кала. Әтисе мәҗбүриләбрәк бирсә дә, алар бер-берсен ошаталар. Чөнки Мөгаммәтгариф прогрессив карашлы кеше була. Алар бергә нибары 14 ай яшәп калалар.

> Ходай кайбер кешеләрне билгеле бер вазыйфаны башкару өчен ярата дип уйлыйм. Әйтик, Мәрьям ана бар. Ул гыйффәтле килеш 13 яшьтә Гайсә пәйгамбәрне таба һәм бераз яшәгәннән соң, дөньядан китеп тә бара. Безнең Бибимәмдүдә дә нәкъ шулай. Ул – фәкать татар халкына Тукайны тудыру өчен яратылган изге зат.

:: Тукайның шагыйрь булып китүендә аның йогынтысы зур, дип әйтә алабыз бит?

– Әлбәттә. Ләкин Тукайның шагыйрь булып китүендә аның бабасы Зиннәтулла хәзрәтнең дә өлеше зур. Зиннәтулла хәзрәт Зәйнелбәшир улы Әмирханов 1829 елда Уфа губернасының Уса өязе Кожмакты авылында (хәзерге Пермь өлкәсенең Барда районы) туа. Үсеп буй җитүгә, Казан янындагы мәшһүр Кышкар мәдрәсәсенә укырга килә. Бу урында бер четерекле мәсьәләне ачыклап китик әле. Зиннәтулланың Уфа губернасына караган авылда тууын сәбәп итеп, кайбер башкорт дусларыбыз аны үз милләтенә теркәп куярга омтыла. Хәлбуки Кожмакты – татар авылы. Аннан соң, «Габдулла Тукай энциклопедиясе»ндәге мәгълүматка караганда, Әмирхан бабайның чыгышы белән Татарстанның Спас районындагы Ямбакты авылыннан булуы бик ихтимал.

Зиннәтулла хәзрәт бик укымышлы, үзе дә шигырьләр яза. Аның Бибимәмдүдә вафатыннан соң язган шигыре сакланып калган. Ләкин башка мирасының кайдалыгы билгесез. Хәзрәт хуҗалык кешесе булмаган, рухи дөнья белән яшәгән. Үзе иҗат иткән, мәшһүр әсәрләрне, дастаннарны күчереп язып, халыкка тарату белән шөгыльләнгән. Бай мирасын үзе исән чакта Хәсәнгата Габәшигә – беренче татар операсын язган композитор Солтан Габәшинең әтисенә васыять итеп калдыра. Ләкин мирас җебе шушы васыять турындагы хәбәрдән соң өзелә. Васы-

«БИБИМӘМДҮДӘ АБЫСТАЙ» КИТАБЫННАН КЫЗЫКЛЫ ФАКТЛАР

✓ Без Бибимәмдүдә белән Мөхәммәтгарифны архитектор Әлфия Зәбирова (Тукайның ата бер, ана башка Газизә апасының оныгы) ясаган график портретлардан күреп беләбез.

✓ Әтисе Мөхәммәтгариф ягыннан карт бабасы Туктулы атлы булганга, Габдулла аны бераз үзгәртеп, Тукай дигән тәхәллүс алган.

✓ Әлеге китап Тукайның анасына багышланган бердәнбер китап булып кала бирә.

ять үтәлгәнме, әсәрләре кайда ята – бу хакта белүче юк.

Бу урында тагын бер борчулы мәсьәләгә тукталып китик. Сүз дә юк, Тукай турында күп языла, күп сөйләнелә. Башлыча бу аның иҗатына кагыла. Тукайга таянып, кемдер диссертация яклый, кемдер доктор, кайсыдыр кандидат дәрәҗәсен ала, ягъни «үсә». Ул яктан Тукай – бәхетле шагыйрь. Ләкин аның тәрҗемәи хәле турында бер фәнни эш тә эшләнмәгән. Ә бит чит илләрдә үз кумирларының һәр сөягән ачыклап язган эшләр бар. Ә без, Тукай, дибез...

:: Китапка сыеп бетмәгән фактлар бармы?

– Ачылмаган сәхифәләр бик күп әле. Әйтик, без Тукайны ярлы булган, дип әйтәбез. Ярлы булмаган ул. Васыятен искә алыйк. Ул үзенең 500 сум акчасын (ул вакытка зур сумма) милли уку йортында укучы шәкертләргә васыять итеп калдырган була. Бу да – өйрәнелмәгән сәхифәләрнең берсе. Кем аның стипендиаты, Тукай акчасын файдаланып укучы, гомумән, булганмы – шулай ук билгеле түгел. Тукайның вафатыннан соң, әтиләре бер, әниләре төрле булган Газизә апасы, «Кояш» газетасында мәрхүмнең *«биш йөз рубльдан артык акчасы калмыш»* турындагы хәбәрне укыгач, редакциягә үзенең хакыйкый варис булуын белдереп, хат юллый. Димәк, аның үлгәннән соң да бүлешерлек әйберләре дә, акчасы да булган. Бу мәсьәләләр һаман ачык.

Аннан килеп, без Тукайның мәхәббәте дип Зәйтүнәне атыйбыз. Ә бит аны дуслары, шул ук Фатих Әмирханнар, Зәйтүнәгә кадәр дә, аннан соң да өйләндерергә тырышып карыйлар. Кешесе билгеләнә, кайда яшәячәкләре билгеләнә, ләкин бу булмый кала. Фактлары билгеле, эчке дөньясы ачыкланмаган. Болар – без белгәне генә. Без белмәгәне күпме? Ә бит шәхесләр нигезендә шәхес тәрбияләнә.

– Бибимәмдүдә фаҗигасенә бәйле фаразлар да шактый. Аның үлем сәбәбен икенче иреннән күрү бар. Һәрхәлдә, ире кыйнап үтергән дигән фараз безнең көнгәчә килеп җиткән.

– Бибимәмдүдә, Мөхәммәтгариф үлгәннән соң, әтисе өенә кайтып китә. Габдулла – төпчек бала, ир бала һәм нигез дә аңа булырга тиеш кебек. Ләкин Мөхәммәтгарифның тагын бер улы, Мөхәммәтшәрифе бар бит әле. Ул авыру бала була, 17 яшендә бакыйлыкка күчә. Әтисе үлгәндә, бу малай әле исән була. Туганнары, якыннары җыелышып, атасы малын шушы малайга бирергә дигән фикергә килгән булулары мөмкин. Әлбәттә, бу – минем фараз гына. Бибимәмдүдә исә бүлешми, мирас артыннан йөрми, авыр булса да, үги әнисе янына кайтып китә. Әлбәттә, бу – бик әйбәт сыйфат. Ә үги әнисе белән яшь аермасы – нибары 4 ел.

Бәлкем Латыйфа абыстайның холкы корырак та булгандыр, ләкин ул да – игътибарга лаек шәхес. Алты бала тәрбияләп үстергән ана лабаса ул. Әлбәттә, ике хатын-кыз булган өйдә савыт-саба шалтырамыйча тормагандыр. Алай булса да, Мәмдүдә бу йортта 3 ел яши. Кулын сорап килүчеләрне дә кире бора абыстай. Мин генә түгел, галимнәр дә, Мәмдүдә Габдуллага лаеклы әти көткән дип фаразлый. Мөхәммәтшакиргә исә улының язмышын яктырак итү уе белән кияүгә чыга. Аңа – 70 яшь, Мәмдүдәгә – 25. Кыйнаган, коры булган, көнләшкән дигән сүзләр, чыннан да, бар. Ике-өч айдан соң анасы янына алынган Габдулла исә бу хәзрәт турында бик матур сүзләр яза: *«Үги әтиемнең мине сөюе, чәй янында ак күмәчкә кәрәзле бал ягып бирүе, шунда куанганнарым биш минутлык төш шикелле әле дә булса хәтеремдә...»*

Бибимәмдүдәнең үлем сәбәбен эч китү дип язалар. Элек яңа туган баланы теркәүне дә, үлем-җитемне теркәүне дә муллалар башкарган. Бу – мулла сүзләре генә, әлбәттә. Мәсәлән, Мөхәммәтгарифнең үлемен дә эч китү белән бәйләп аңлаталар. Истәлекләрдә исә «үле бала тапкан» дигән фараз да бар. Мин аны бер генә җирдә очраттым, башка истәлекләрдә таба алмадым. Шуңа күрә исбатларга җирлек юк.

:: Сезнең иҗатыгызның күп өлеше тарихи шәхесләргә, бигрәк тә хатын-кызларга багышланган. Моның сәбәбе нәрсәдә?

– Хатын-кызга багышланган әсәрләрем, чыннан да, шактый. Беренче повестем да бит «Гөлнәзирә» дип атала. Аны Аяз Гыйләҗев бик ошаткан иде. Аннан «Мөкәррәмә» повесте, «Каргыш», «Гәүһәршад», «Үрбәк ханның гыйшкы», «Шәһре Бану» – бу әсәрләрнең барысында да үзәктә – хатын-кыз. Ни өчен хатын-кыз? Мөгаен, ул минем эчке халәтемә бәйледер. Мин әтисез үстем. Әти сугышта һәлак булган. Әнкәй мине һәм ике сеңлемне ялгызы үстерде. Ул һәрвакыт эштә, безне нигездә әби-әбекәй тәрбияләде. Ул бик саф күңелле, гадел, ышанучан иде. Безне дә үз үрнәгендә үстерде. Күп сөйләшмәскә, кешегә каршы сүз әйтмәскә... Аның тәрбиясе хәзерге көнгә бөтенләй туры килми. Хәзер калкып чыгарга, тырышырга, көрәшергә кирәк, ә безне башны ияргә өйрәттеләр. Аннан укырга кердем, пединститутта да башлыча кызлар гына укыды. Без берничә генә егет идек. Мәктәптә эшләгәндә дә, «Сөембикә» журналында да хатын-кызлар арасында булдым. Егерме елдан артык хатын-кыз проблемаларын өйрәндем, дияргә була.

Әйтергә кирәк, хатын-кыз – ихтирамга иң лаеклы зат. Хатын-кыз ниндидер сүз әйтә икән, ул аны эшли. Ир-атлар турында алай әйтеп булмый.

:: Марат абый, сезгә бүген 89 яшь тулды. Үткән гомергә карап, шөкер итәрлекме? «Халык язучысы» дигән исем бирелмәү, узган ел Тукай премиясен ала алмау үпкәләтмиме?

– Туган көн – минем өчен гадәти көн. Без үскәндә, аны бәйрәм итү юк иде. Миңа шулай сеңеп калган инде ул.

Тукай премиясенә килгәндә, узган елны хәтта рәсми кешеләр дә котлап шалтыраткан иде. «Башта Президентның указы булсын», – дидем. Буласы булган инде. Бу ел исә минем өчен бик авыр булды. Хәләл җефетем бакыйлыкка күчте, үзем дә каты авырдым. Премия мәсьәләсенә кайчан да булса кире кайтырмынмы – әйтә алмыйм. Чөнки холык андый түгел. Ул йөреп ала торган бүләккә әйләнде. Андый гамәлләрне берничек тә кабул итә алмыйм.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

ЛЮЦИЯ ӘБЛИЕВА

СӨЕП, СӨЕЛЕП ЯШИСЕМ КИЛӘ! (ХИКӘЯ)

< Дәвамы. Башы 15 апрель санында

Зарифа белән Хәдичә гәүдә төзелеше, төс-баш белән генә түгел, холык-тәрбия белән дә бер-берсеннән аерылып тордылар. Буйга озынча, тәнгә юкарак Хәдичә белән туп кебек кабартылган Зарифа, читтән караганда, берсе «Багана» булса, икенчесе «Кәтүк» иде. Артык ыспайлык яраткан Хәдичәнең дөньясы да, үзе дә гөл кебек балкып торса, ахирәтенең чисталыкка бик һушы китеп бармады. Дүрт малай үстерүен сылтау итеп: «Бер генә кызым булса да, өйләрне җыештырыр иде, малайларга туздырырга гына булсын», – дип аклана-аклана, шапшак яшәвен дәвам итте. Хәдичәнең тәмле ашлары белән сыйланганда: «Булмый инде миннән, булмый, җыештырсам да, синеке кебек культур-мультур килеп чыкмый, пешерсәм дә болай уңмый, аның өчен яңадан туарга кирәк», – дип, ахирәтен мактап җибәрергә дә онытмады. Хәдичәнең бүлдерми-нитми тыңлавы, сүз йөртмәве, сирәк кенә «чәйгә» сугылып чыгуы газ-плитә тирәсен яратмаган Зарифага кулай иде. Гаиләсендәге ир-ат көн саен пешерелгән токмачлы ашка, каймак-кайнатма ягылган ипи белән эчкән чәйгә риза булгач, артыгын биемәде. Дөрес, сирәк-мирәк булса да, бәлеш, гөбәдия, кыстыбый кебек әйберләрне дә әзерләштерде, тик Хәдичәнеке кебек ашап туймаслык килеп чыкмый иде шул алар. Күрше районнан килен булып төшкәнгәме, холкы шулаймы, авыл кешеләренә карата Хәдичә битараф булды. Бәлки, дини бианасының килен булып төшкәч үк: «Өй эчендәге урамга чыкмасын, урамдагы өйгә кермәсен», – дигәне йогынты ясагандыр. Ә Зарифа киресенчә: бөтен авылның хәбәре аңарда булды. Аларның дуслыгына авыл халкы әллә ни аптырамый, чөнки шәхес культы чоры әллә кая ерак китмәгән, аны хәтерләүчеләр байтак кына иде әле. Бөек Ватан сугышы елларында Фазылгаянның әнисе җигеп җир сөргән колхоз үгезе егылып үлгәч, атасы аны төрмәдән алып калганга, Зарифа бу йортта кадер-хөрмәттә утыра, тупсага тузан төшерми.

Өстәл яныннан Хәдичә ахирәтенең һәр әйткәненә ихлас ышанып, колхоз малына кул сузган күршеләрен җәзага тарттырырга кирәклегенә ышанып кузгалды. Шул кичне үк халык контролен җитәкләгән иренә барысын да түкми-чәчми җиткерде. Артыгын сөйләргә яратмаган Фазылгаян тын гына утыруын дәвам итте.

– Я инде, авызыңа су капкандай торасың, ни уйладың?

– Уйладың дип... Утсыз төтен булмый, кәнишне, уйларга кирәк, хуҗалар белән киңәшләшермен.

– Юк, юк!!! Әлегә беркемгә дә әйтергә кирәк түгел. Әгәр дөрескә чыкмаса, кеше алдында рисвай булырбыз, Аллаһ сакласын!

– Аңламыйм мин сине, бичә. Ярты сәгать элек кенә күршеләрне каракка чыгардың, хәзер үзеңә каршы киләсең.

– Соң тикшерми-нитми генә, ничек яла ягасың кешегә? Әнә, Зарифа әйткәнчә, башта күзәтик, дөрескә чыкса, җиткерерсең кирәк җиренә.

Дөресен генә әйткәндә, Фазылгаянның үзенең дә күршедә кинәт кенә калкып чыккан йорт, килеп-килеп, эчен тырнаштырып ала иде. «Ятим Фәридә малае да димәссең! Хатыны да туры килгән. Бер бала белән дә әллә ни үсенеп булмый, болар өч бала белән, нинди зур йорт салып керделәр», – дип, беркөн каенишенә дә ычкындырган иде. Тик төптән икенчерәк уйлый иде ул: «Бригадир булып йөргән булабыз инде өч тиенлек зарплатка, механизаторлар әнә каерып алалар акчаны. Исемебез бар, җисемебез юк. Аның өстенә халык күзәтүчесе итеп сайлап куелганбыз, ни нәливе, ни направы, диярсең. Шулай инде, һәркемнең – үз ризыгы. Керәм дисә, авызны каерып керә, юк икән, теге мәзәктәге кебек, ай буе көтү көткән акчаңны да бирмиләр».

Икенче көнне сигезенчедә укып йөргән кызлары Мәһинурга «задание» бирелде: «Дәрестән кайтып тамак ялгагач, күзеңне тәрәзәдән алма. Сабир абыең белән Таһирә апаңнарның ихатасына трактор, машина, арбалы ат-мазар кергәнне карап-күзәтеп тор. Вакытын, числосын күрсәтеп, бөртекләп аерым дәфтәргә язып та бар, яме».

* * *

Мәһинур, күрер күзгә әллә ни чибәрлеге белән аерылып тормаса да, кыз кеше буларак яшьтәшләреннән тизрәк өлгерде. Бишенчедә укыганда ук егетләрнең, җае туры килгән саен, куллары аның күкрәкләре янында уйнады. Гаиләдә бердәнбер бала булгангамы, кием-салым ягыннан да башкалардан аерылып тора иде ул. Укытучыларның да әле күбесенә тәтемәгән «балон» плащ, очлы башлы үкчәле туфлиләр, клеш чалбарлар, чәчәкле кримплен күлмәкләрне әтисенең Чиләбедә яшәгән бертуган апасы посылка белән җибәреп кенә торды. «Агач күрке – яфрак, кеше күрке – чүпрәк» дигәндәй, гади киемле тал чыбыгы кебек кызлар янында Мәһинурның тулы гәүдәсе чибәррәк күренде. Алай гына да түгел, мыек чыгара башлаган егетләр өчен дә ул бик ымсындыргыч кызга әйләнде. Алтынчыда укыганда ук кинодан соң озатырга теләүчеләр күренә башлады. Үзләрендә мәктәп сигезьеллык кына булганга, күрше авылда, югары сыйныфта укып йөргән егетләр бигрәк тә аңа ныграк тартылды. Тик Мәһинур әти-әнисеннән шүрли иде. Шуңа күрә, берсен дә якын китермәде: егетләрне тәпәләп дигәндәй, кереп кача иде. Беренче ярату хисләрен сигезенче сыйныфка күчкән җәйне кичерде. Әнисе ягы туганнарына кунакка баргач, армиядән яз кайткан Фәнис исемле егет кинодан соң аны озатып килде. Иреккә чыккан кош баласы саклыкны онытып җибәргән шикелле, Мәһинур да чит авылда әти-әнисенең таләпчән карашын арткы плангарак күчерде. Аның да олы кызлар кебек «свиданҗе»ләргә йөрисе, егетләр белән очрашасы килә иде. Яшь аралары шактый гына булганга, түтәй тиешле апасы очрашуларына башта карышып караган иде дә, тыңлата алмады. Аннан: «Капка төбеннән ерак китмибез!» – дигән сүзләренә ышанып, бераз йомшарды. Беренче караштан туган мәхәббәт булдымы, икесенең дә күңелләренең бер дулкында тибрәлүе идеме, алар бер-берсенең кочагына бик теләп тартылдылар.

Дәвамы бар >

Язучы фикере

КАР ӨЕМЕ

Тормыш законы ук түгелдер инде бу, сәерлекнең берәр билгесе генәдер. Әмма миңа кызык тоелды.

Яз исе килә башлагач, аның үзен дә тизрәк күрергә омтыласың бит. Кышын көрәп өйгән карны кире таратасың. Шулай итсәң, тизрәк эреп бетәр төсле тоела. Кар эрегән урыннарда үлән калкына, язының борыны күренә башлый. И рәхәт инде ул. Тау башларына карасаң да, кардан ачылган урыннар күзне иркәли. Хас менә йомырка кабыгын тишеп чыгучы каз бәбкәсе. Башта коңгыртрак булып, томшыгы күренә, аннан саргылт йонналары... Яз да шулай каз бәбкәсе шикелле кар кабыгын тишеп чыгадыр сыман.

Кар эреп бетте бер мәлне. Калынрак урынын табып, су савытына да салып куйдым әле. Хатын шулай кушты, гөлләргә, тәрәзә төбендәге яшелчә үсентеләренә сибәргә әйбәт, ди. Кыш буена күрмәгән теге карны, аның гөлгә файдалы икәнен белмәгән, кар бетә башлагач кына исенә төшкән. Кар эреп бетте ишегалдында, дип яз кәефе белән балкып йөргәндә, күз төште аңа. Бакчаның бер почмагында калын гына өем кар калган. Урыны шундыйрак, кояш төшә торган түгел. Кояш та төшми, җил дә ашамый. Шуңа теге кар өеме, мине ирештергәндәй, күкрәген киереп утыра. Менә мин, имеш, хәтта яз кояшына да бирешмим!

Үткән-сүткәндә күз салып узам. Таратып ташларга кирәк, дип уйлыйм. Тик аңа кул җитми. Әллә ни мөһим нәрсә дә түгел бит инде, язмышы котылгысыз, барыбер эреячәк. Аның белән маташып торуның мәгънәсе юк. Әле монда мөһимрәк эшләргә дә өлгереп бетеп булмый. Аңлыйм мин барсын да. Тик теге кар өеме барыбер эчне пошыра. Төгәлләнеп бетмәгән эш кебек бит инде. Менә син, әйтик, роман тиклем роман язгансың да аның соңгы җөмләсен язмыйча калдыргансың. Зыяны юк: нәрсә язарга икәнен беләсең, вакыт та күп кирәкми. Тик барыбер эшем бетте дип җиңел сулый алмыйсың, чөнки бер җөмләсе тәмамланмый калган. Яки менә индыр тутырып бәрәңге утырткансың да бер кишәрлек җиргә кулың җитми калган. Теләсә кайчан утыртып була аны. Ярты сәгатьлек эш. Ләкин ул эш эшләнеп бетмәгән. Шуңа эчеңне пошырып тора.

Кар өеме белән дә шундый ук хәл. Эчне пошырудан азып, ул инде ачуны китерә башлый. Кичен арыта бераз, вакыт та соң. Иртәгә иртүк таратып ташлыйм дип ятасың да, иртән тагын яңа мәшәкать табыла, аның кайгысы калмый. Шулай итеп көн уза, кичен тагын теге карга күз төшә. Аз гына бирешкән кебек, тик барыбер таратырга кирәк. Бу хәл хәзер көн саен кабатлана. Кар өеме инде шайтан кебек күренә башлый. Ул кар өеме түгел, ә синең булдыксызлыгыңа, сүзеңдә тора алмавыңа, ялкаулыгыңа куелган һәйкәл шикелле тоела. Бу уйларны куарга тырышсаң да, кар өеме барыбер кала. Аны күргән саен җенең котыра. Нәфрәтеңнән ялкын кабынса, билләһи, шуны эретеп агызыр иде.

Кайвакыт шундый кешеләр дә очрый ул. Очрашасың, күрешәсең һәм бер сәбәпсез яратмый башлыйсың. Ул әле авыз ачып сүз дә әйтмәгән, хәтта исемен дә белмисең, ләкин аның булуы синә уңайсызлык тудырган кебек. Черки шикелле менә. Ул сине тешләмәгән әле, хәтта бер җиреңә кунмаган да, хәтта безелдәми дә. Тик син инде тормыш җаен югалтасың һәм теге черкине куып җибәрергә омтыласың. Ләкин кеше черки түгел, аны бер сәбәпсез куып җибәреп тә, бәреп үтереп тә булмый. Һәм ул, шуннан явыз ниятта файдаланып, синең каныңны бозуын дәвам итә. Моның сәбәбен мин берничек тә аңлата алмыйм. Феномен бугай бу.

Кар өеме дә шундый феноменга әйләнде. Мин күз салып узам. Кайчагында хәтта махсус чыгып карыйм. Ләкин таратырга вакыт юк. Ә ул ачуны кабарта. Гаҗәп!.. Бер зыяны да юк бит инде югыйсә. Тавышы да, исе дә юк. Хәрәкәтләнми дә. Ята шунда үз вакытын көтеп. Карама, күз дә салма. Уйлама аның турында. Үз вакыты җиткәч, юкка чыгачак, язмышы күптән хәл ителгән. Юк! Алай булмый. Уйлыйсың, карыйсың, нәфрәтләнәсең. Куралмый башлыйсың...

Бер-ике көн яңгыр яуды да өйдәге эшләр белән генә маташырга туры килде. Бакча тирәсенә бармасам да, теге кар өеме – барыбер күз алдында. Тере картина кебек. Күз алдына килеп баса да ачуны чыгара. Менә шушы эшне генә тәмамлыйм да чыгып таратам дип уйлыйсың. Тик үзең дә сизмичә, икенче эшкә тотынып китәсең.

Әле менә чыгып карадым. Теге кар өеме эреп беткән. Тик мин тамчы да сөенә алмадым. Күңелдә юксыну тойгысы гына. Иң якын дустымны югалткан шикелле. Мәңге дә кире кайтмас инде ул. Узган кышның соңгы кыйпылчыгы иде бит. Әллә нинди кадер-хөрмәт күрсәтә алмыйм инде аңа, тик карашларым белән булса да назлап узарга кирәк булган. Бәлки ул мин көзен күреп сокланган беренче кар булгандыр. Һәм соңгысы... Кышның соңгы кары... Минем кышның...

Сәер халәт шундый... Тормыш кануны ук түгелдер инде бу, ахмаклыкның берәр чагылышы гынадыр...

Марат КӘБИРОВ



15 апрель санында чыккан сканвордның җаваплары
Горизонталь буенча: Шопен, асс, Карен, тәк, пирога, Коко, вольт, лавсан, укра, Борай, Ани, Боярская, кирза, Вәлиева, Антиб, Коми, мандат. **Вертикаль буенча:** бивак, полк, Ом, Икария, лама, Шакирова, Инин, аскет, Парагвай, киви, аноа, Арабат, Нант, Раяз, Эльтон, сак, биз.

Викторина

Тәкъдим ителгән һәр сорауда җавапларның өч варианттан берсе генә дөрес. Берсен сайлап, белемегезне тикшерегез.

1 Казан шәһәре мэры Илсур Метшин үз вазыйфасына ничәнче елда керешә?
А) 2001;
Б) 2006;
В) 2010.

2 1550 елда яңа законнар җыентыгы эшләнә. Аның исеме...
А) «Троица»;
Б) «Кодекс куманикус»;
В) «Хөкем китабы» («Судебник»).

3 Император Николай IIнең идарә итү еллары.
А) 1894–1917;
Б) 1861;
В) 1881–1894.

4 «Конституция» сүзе латинча нәрсә дигәнне аңлата?
А) хокук;
Б) төзү, урнаштыру;
В) берләшү.

Җаваплар: 1) Б; 2) В; 3) А; 4) Б.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Индекс П2435
Тираж – 16091 данә
Газетага сертификат бирелде
Заказ 257

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкаләл авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+